| | | | 7. Тәрбияче апаларның «Яшел докторлар» спектакелен карау. | 1. Танып белү эшчәнлеге.<br>2. Музыка. | |
| 3. | «Җәй».<br>Максат: Җәй турындагы белемнәрен һәм күзаллауларын гомумиләштерү.<br>Бурычлар:<br>• җәйге табигатькә сакчыл караш тәрбияләү;<br>• җәйге куркынычсызлык | 23.05. – 31.05. | 1. Җәйге болынга экскурсия. | 1. Танып белү эшчәнлеге.<br>2. Сәламәтлек.<br>3. Куркынычсызлык кагыйдәсен үтәү. | |
| | | | 2. Асфальтта балалар рәсеме. | 1. Нәфәсәти сәнгать.<br>2. Куркынычсызлык кагыйдәсен үтәү.<br>3. Музыка. | |
| | кагыйдәләре турында белемнәрен үстерү; балаларны җәйге спорт төрләре белән таныштыру. | | 3. Әтиләргә комлыкта уйнар өчен атрибутлар ясату. | 1. Танып белү эшчәнлеге.<br>2. Аралашу.<br>3. Физкультура. | |
| | | | 4. Тәҗрибә участогында эш (яшелчәләр чәчү). | 1. Танып белү эшчәнлеге.<br>2. Куркынычсызлык кагыйдәсен үтәү.<br>3. Музыка.<br>4. Хезмәт. | |
| | | | 5. Җәй турында җырлар өйрәтү. | 1. Танып белү эшчәнлеге.<br>2. Музыка.<br>3. Аралашу. | |
| | | | 6. «Ямьле җәй житә» темасына | 1. Танып белү эшчәнлеге.<br>2. Нәфәсәти сәнгать.<br>3. Физкультура. | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | күмәк аппликация. | | |
| | | | 7. Җәй турында шигырьләр. | 1. Танып белү эшчәнлеге.<br>2. Музыка.<br>3. Матур әдәбиятны уку. | |
| | | | 8. Җәйге спорт уеннары. | 1. Танып белү эшчәнлеге.<br>2. Куркынычсызлык кагыйдәсен үтәү.<br>3. Физкультура.<br>4. Сәламәтлек. | |
| | | | 9. Җиләкҗимеш бакчасында эш. | 1. Танып белү эшчәнлеге.<br>2. Куркынычсызлык кагыйдәсен үтәү.<br>3. Музыка.<br>4. Хезмәт. | |
| | | | 10. Әрәпә җыю. | 1. Танып белү эшчәнлеге.<br>2. Куркынычсызлык кагыйдәсен үтәү.<br>3. Музыка.<br>4. Социализация. | |
| | | | 11. Сабантуй. | 1. Танып белү эшчәнлеге.<br>2. Куркынычсызлык кагыйдәсен үтәү.<br>3. Музыка.<br>4. Социализация. | |

ФГОС таләпләренә туры китереп оештырылган **белем бирү өлкәләре** түбәндәгечә:

| Оештырылган белем бирү өлкәләре | Саны |
|---|---|
| Танып белү үсеше. Төзү һәм тәҗрибә эшчәнлеге. ФЭМП һәм әйләнә – тирә белән танышу | 4 |
| Сөйләм эшчәнлеге (матур әдәбият белән танышу) | 1 |
| Иҗади – эстетик үсеш. Сәнгать үсеше. Рәсем, ябыштыру. Җыр | 0,5 /0,5<br>2 |
| Физик үсеш (Физик культура, сәламәтлек) | 3 |
| Социаль– шәхсиүсеш (Хезмәт һәм куркынычсызлык, социальләштерү) интеграция эчендә | |
| Барлыгы: | 11 |

## 2. Белем өлкәләре буенча комплеклы - тематик план

### 2.1. «ФИЗИК ҮСЕШ» *Сәламәтлек*

***Аңлатма язуы***

«Сәламәтлек» белем бирү эшчәнлеге эчтәлеге балаларның сәламәтлеген саклау, аларда сәламәтлек культурасы нигезләрен формалаштыру максатларын тормышка ашыруга юнәлдерелә һәм белем бирү бурычларын билгели.

Балаларның физик һәм психик сәламәтлекләрен ныгыту буенча эшне; оешма төрен һәм тибын, булган шартларны, төркем тулылыгын, балаларның сәламәтлек һәм үсеш үзенчәлекләрен, шулай ук төбәктәге климатик һәм ел фасыллары үзенчәлекләрен исәпкә алып, бала организмын чыныктыру эшен дәвам итү.

Шәхси гигиена процесслары турындагы күзаллауларын баету. Гигиена нормалары һәм кагыйдәләрен аңлы һәм мөстәкыйль рәвештә үтәүләренә ирешү.

Гади һәм чиста киенү, киемнәрне тәртипләп төрү, бүлмәдә чиста аяк киемендә йөрү күнекмәләрен үстерү.

Ашаганчы һәм ашагач, пычрангач, туалеттан соң кулларын мөстәкыйль рәвештә юарга, тешләрен чистартырга, ашаганнан соң авызны чайкарга, йоклар алдыннан аякларны юарга гадәтләндерү.

Пөхтә ашау күнекмәләрен камилләштерү: ризыкны азлап кына алу, тавышсыз гына ашау, бик кайнар ризык ашамау, коймау, савыт-сабаны дөрес файдалану.

Милли ризыклар һәм эчемлекләр (умач, татарча азу, казам пылавы, кара җимеш һәм өрекле чәй, хуш исле чәй һ. б.) белән таныштыру.

Бала организмы өчен кирәк булган витаминнар турында күзаллау булдыру. Ризык кабул итү режимын үтәү, җиләк-җимеш, яшелчә, балык һәм сөт ризыкларын (кайнаган сөт, кефир, корт), ит һәм башка файдалы ашамлыкларны куллануга ихтыяҗ тәрбияләү.

«Сәламәтлек» һәм «авыру» төшенчәләре, халык медицинасының кайбер чаралары белән таныштыру. Бәрелгәндә, киселгәндә үз-үзеңә һәм башка балаларга элементар ярдәм күрсәтү, үз сәламәтлегең турында кайгырту күнекмәләре формалаштыру.

***ЙОКЫДАН УЯНУ ГИМНАСТИКАСЫ***

***Комплекслы-тематик план***

| **ай** | **гимнастика** |
|---|---|
| сентябрь | «Уяну»<br>Йокы качты тәрәзәдән, йөгерде юллардан,<br>Ә без синен белән уяндык, уяндык та елмайдык (киерелү)<br>Башта күзләрнен берсен ачтык, аннары икенчесен, |
| | Кулларны күтәреп төшердек, велосипед әйләндердек. Уңга-<br>сулга борылдык, аннары сикереп тордык. |
| октябрь | «Хәерле иртә»<br>Хәерле иртә, күзләр. Сез уяндыгызмы?(күзләргә массаж. Бармаклар белән бинокль ясап, як-якка карыйлар)<br>Хәерле иртә, колаклар. Сез уяндыгызмы?(колакларга массаж. Учны колакларга куялар (“Чебурашка”), якякны тыңлыйлар)<br>Хәерле иртә, куллар. Сез уяндыгызмы?(кулларның башта берсенә, аннан икенчесенә массаж. “Пропеллер” күнегүе)<br>Хәерле иртә, аяклар. Сез уяндыгызмы?( аякларның башта берсенә, аннан икенчесенә массаж. “Велосипед” күнегүе)<br>Хәерле иртә, кояш. Мин уяндым!( кулларны сузып киерелү) |

| | |
|---|---|
| ноябрь | Әйдәгез, бергәләп, басабыз,<br>Кулларны ян – якка сузабыз.<br>Аннары бөгеләбез,бергәләп тураябыз.<br>Кулларны күтәрәбез,<br>Кояшка сәләм юллыйбыз.<br>Кулларны качырабыз,<br>Аннары аларны бергәләп<br>эзлибез. Уңга карыйк, Сулга<br>борылыйк.<br>Утырабыз, торабыз.<br>Үкчәгә дә басыбыз,<br>Аяк очларына басып,<br>Кояшка үреләбез. |
| декабрь | «Без шулай итәбез»<br>Без йоклап тордык, бераз уйнарга булдык.<br>Башны иябез алга, уңга, сулга борабыз,<br>Аннан карап торабыз.<br>Иң өсләрен сикертәбез, кулларны биетәбез. |

| | |
|---|---|
| | Бер алга, бер артка сузып,<br>Күңелле ял итәбез.<br>Аннары без чүгәлибез, тезләрне кочаклыйбыз.<br>Башны алга яшереп, без ападан качабыз. |

| | |
|---|---|
| январь | «Пескәй »<br>1. “Пескәй уяна”. Ятып, бергә уң аякны һәм сул кулны күтәрәләр, төшерәләр. Аннан сул аякны һәм уң кулны күтәрәләр, төшерәләр. Аннан 2 кулны һәм 2 аякны бергә күтәрәләр, төшерәләр. 4-5 тапкыр кабатларга.<br>2. «Пескәй сөенә». Үрмәләү позасына керергә. Башны күтәрергә, умыртка сөяген бөгәргә. Тирән сулыш алырга. 4-5 тапкыр кабатларга.<br>3.«Пескәй ачулана ». Үрмәләү позасына керергә. Иякне күкрәккә тидерергә, арканы бөгәргә. Тирән сулыш алырга. 4-5 тапкыр кабатларга.<br>4. “Пескәй сузыла” Сузылу күнегүе.<br>5. “Пескәй сикерә” Сикерү. |
| февраль | “Чәчәк”<br>Чәчәк йоклый,<br>Чәчәк уяна. (киерелү күнегүләре)<br>Иртәнге кояшка<br>Ул бик куана. (урында сикерү)<br>Кояшка сузыла (аяк очларына басып, сузылалар)<br>Кояшка үрелә (аяк очларына басып, сузылалар)<br>Күбәләк дустына (кулларны канатлар каккан кебек җилпиләр) Сәлам<br>өләшә (сәлам бирәләр) |
| март | Без уяндык, (киерелү күнегүләре)<br>Күзләрне ачтык, (күзләрен ачалар)<br>Аякларны суздык (аякларын сузып, селкетәләр) Аларны<br>да уяттык!<br>Ян –якка борылып (басып, ян –якка борылалар) |

| | |
|---|---|
| | Кояшка без карадык. (аяк очларына басып, сузылалар) Якты<br>көнгә сокланып, |
| | Матур итеп елмайдык. (ян – якка борылып, елмаялар)<br>Сикереп тә алдык (сикерү күнегүләре)<br>Йөгердек тә (урында йөгерү)<br>Хәзер инде без<br>Уйнарга бергә әзер! (үз-үзеңне кочу) |
| апрель | Аякларың тыпырдат (аякларны тыпырдаталар)<br>Кулларыңны чәбәклә.(кулларны чәбәклиләр)<br>Бер монда, бер монда,<br>Кыен эш түгел бер дә. (ян-якка борылып кулларны чәбәклиләр)<br>Башың аска иеп ал, (башларын бер иеп, бер күтәрәләр)<br>Кулларыңны болгап ал. (йөзү күнегүләре)<br>Бер монда, бер монда,<br>Кулларыңны болгап ал.(ян- якка борылып, йөзү күнегүләре эшлиләр)<br>Бу дустың белән күреш, (уңга борылып, сәләм юллыйлар, елмаялар)<br>Бу дустың белән күреш.(сулга борылып, сәләм юллыйлар, елмаялар)<br>Йә иптәш, йә, әйлән, (урында сикереп, әйләнәләр) Бик кыен түгел бу<br>эш. |

| | |
|---|---|
| май | Нәниләр бара тигез юл буйлап. (урында атлыйлар)<br>Тигез юл буйлап, ашыкмый атлап. (урында атлыйлар)<br>Зур-зур ташларны<br>Сикереп үтәләр. (урында сикерәләр)<br>Уңга да баралар, сулга да баралар, (уңга – сулга борылу күнегүләре)<br>Су аша йөзеп, (йөзү күнегүләре) ярга чыгалар. (сулыш алу<br>күнегәләре) |

### *ФИЗИК КУЛЬТУРА*

### *Аңлатма язуы*

«Физик культура» белем бирү эшчәнлеге эчтәлеге балаларда физик культурага кызыксыну һәм аңлы караш, гар-монияле физик үсеш формалаштыру максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели.Балаларда хәрәкәт активлыгына ихтыяҗ формалаштыру. Яшьтәшләре белән зур булмаган төркемнәрдә, үзләре белеп, татар халык уеннарын оештыруда мөстәкыйльлекләрен үстерү. Кагыйдәләрне мөстәкыйль рәвештә үтәргә өйрәтү.Хәрәкәтләнү тәҗрибәсен баету.Хәрәкәтле уеннарда балаларның иҗади сәләтләрен (уен вариантлары, катнаш хәрәкәтләр уйлап чыгару) үстерү.

### *САФ ҺАДА ХӘРӘКӘТЛЕ УЕННАР*

Хәрәкәтле уеннар балаларның физик үсешенә булыша, сәламәтлекләрен ныгыта, хәрәкәт координациясен яхшырта. Әлеге уеннар ярдәмендә бала тырыш, көчле, сәләтле, нык ихтыярлы булып үсә. Бу уеннарны уйнаганда билгеле бер кагыйдәләрнең үтәлү мәҗбүрилеге балаларны тәртипкә, үз эш гамәлләр, хәрәкәтләрен барларга өйрәтә. Уенның шартларын истә калдыру аша балаларда күзәтүчәнлек тәрбияләнә, истә калдыру сәләте, хәтер эшчәнлеге яхшыра. Уен бапрышанда балалар бергәләп уйнау, хәрәкәт итү, ситуацияне хәл итү кебек күнекмәләргә өйрәнәләр, башка балалар арасында үзеңне тоту, гомуми кагыйдәләргә буйсыну кебек тәртип кагыйдәләрен үзләштерәләр. ***Комплекслы-тематик план***

| Ай | Атна | Тема | Бурычлар |
|---|---|---|---|
| сентябрь | I | «Аю өне янында» ”Куяннар һәм бүре” | Сикерү күнекмәләрен үстерү, сыгынучанлыкны, җитезлекне булдыру, сиганал буенча хәрәкәтләрне төгәл башкарырга өйрәтү. |
| | II | «Светофор һәм автомобиль» | Бирелгән темп белән хәрәкәтләнергә өйрәтүне дәвам итү. Юлдагы куркынычсызлык кагыйдәләрен ныгыту. |
| | | «Трамвай” | Игътибарлыкларын тупларга күнектерү, түземлек тәрбияләү, уен кагыйдәсен үтәргә өйрәтү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | III | «Огуречик»<br>“Көтүче һәм көтү” | Йөгерү тизлеген үстерү,сигнал буенча хәрәкәт итү,шигырь сүзләренә туры китереп уйнау, күзәтүчәнлекне үстерү. |
| | IV | «Песи һәм тычкан» | Пространствода ориентлашу, бәрелми – төртелми уйнауны булдыру. |
| | | “Очкычлар” | Төрле юнәлештә йөгерү күнекмәләрен системалаштыру, дус –тату уйнауны булдыру. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Октябрь | I | “Ябалак” | Игътибарлылык, кыюлык, җитезлек кебек матур сыйфатлар тәрбияләү, шигырь сүзләренә туры китереп уйнау. |
| | | “Төсле автомобильләр” | Юл йөрү кагыйдәләрен ныгыту, төсләр турында белемнәрен камилләштерү, сиганал буенча хәрәкәтләнүне булдыру |
| | II | “Кыңгырау” | Дус – тату уйнауны булдыру, түгәрәк тирәли сиганал буенча йөгерү күнекмәләрен, тизлекне үстерү, |
| | | “Инеш аша сикереп чык” | Урыннан 2 аякта ераклыкка сикерү күнекмәләрен камилләштерү, кыюлык тәрбияләү |
| | III | “Куяннар” | Сикерү күнекмәләрен камилләштерү, уен барышында иптәше белән хәрәкәтләрне яраклаштырып башкару күнекмәсен үстерү. |
| | | “Машиналар һәм җәяүлеләр” | Юл йөрү кагыйдәләре турында белемнәрен ныгыту, тирә-якта ориентлашу күнекмәсен үстерү,игъбарлылык тәрбияләү |
| | IV | “Беренче булып бас” | Игъбарлылык тәрбияләү, тырышлык, максатчанлык кебек яхшы сыйфатларны үстерү, физик активлыгын камилләштерү. |
| | | “Аю-бүре” | Йөгереклек һәм җитезлек сәләтен үстерү,сүзләргә туры китереп хәрәкәтләр ясау. |
| ноябрь | I | “Казлар - аккошлар” | Игътибарлыкларын, хәтерен, кузаллауларын үстерү, рольләрне бүлешкәннән соң дөрес башкаруны булдыру, пространствода бәрелешмичә төрле юнәлештә йөгерү күнекмәләрен камилләштерү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | “Сиздермичә йөгереп үт” | Сизгерлек булдыру, дус –тату унарга өйрәтүне дәвам итү. |
| | II | “Тавык кетәклегендә төлке” | Җитезлек, өлгерлек тәрбияләү, тиз йөгерү, сикереп менү күнекмәләрен бирү. |
| | | “Үз төсеңне тап” | Хәтерне, җитезлекне үстерү,балаларны иптәшләренә карата кайгыртучан, игътибарлы, ярдәмчел булырга өйрәтүне дәвам итү, кешелеклелек хисләре тәрбияләү. |
| | III | “Көн-төн” | Коллективта бергә уйнау теләге уяту, пространствода ориентлашу булдыру**,** сигналларга игътибар итү, ишетү сәләтен үстерү. |
| | | «Светофор һәм автомобиль» | Бирелгән темп белән хәрәкәтләнергә өйрәтүне дәвам итү. Юлдагы куркынычсызлык кагыйдәләрен ныгыту. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | IV | “Бүләкләр” | Балаларны бер-берсе белән аңлашып кирәк чакта ярдәм итеп уйнарга өйрәтүне дәвам итү, хәрәкәт активлыгын үстерү. |
| | | “Әбәк” | Игътибарлыкларын, хәтерен, кузаллауларын үстерү, рольләрне бүлешкәннән соң дөрес башкаруны булдыру, пространствода бәрелешмичә төрле юнәлештә йөгерү күнекмәләрен камилләштерү. |
| декабрь | I | “Песи һәм кошчыклар” | Хәрәкәт координациясен, җитезлекнее үстерү, уен белән кызыксындыру булдыру. |
| | | “Кайда шалтыраттылар” | Ишетү сәләтен үстерү,реакцияләренең тизлеген көчәйтү. |
| | II | “Кем беренче?” | Йөгерү тизлеген үстерү, максатка ирешүчәнлек кебек яхшы сыйфатлар тәрбияләү. |
| | | “Машиналар һәм җәяүлеләр” | Юл йөрү кагыйдәләре турында белемнәрен ныгыту, тирә-якта ориентлашу күнекмәсен үстерү,игъбарлылык тәрбияләү |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | III | “Аучы һәм куяннар” | Сабырлык, җитезлек, хәрәкәт активлыгы тәрбияләү, пространствода оринтлашу булдыру, рольләрне бүлешеп уйнау күнекмәләрен үстерү. |
| | | “Кегляны аудар” | Төзлекне, тырыш, көчле, сәләтле, нык ихтыярлы булып үсүләренә этәргеч бирү. |
| | IV | “Мине куып җит” | Җитезлекләрен үстерү, бер –бер артлы йөгерү күнекмәләрен булдыру**.** |
| | | “Тавык кетәклегендә төлке” | Җитезлек, өлгерлек тәрбияләү, тиз йөгерү, сикереп менү күнекмәләрен бирү. |
| январь | I | “Миңлебай” | Яшьтәшләре белән зур булмаган төркемнәрдә, үзләре белеп, татар халык уеннарын оештыруда мөстәкыйльлекләрен үстерү, уен кагыйдәсен үтәүне булдыру. |
| | | “Аксак төлке” | Бер аякта сикерү кәнекмәләрен үстерү, җитезлек тәрбияләүне дәвам итү. |
| | II | “Энә һәм җеп” | Җитезлек, өлгерлек тәрбияләү, бер-бер артлы йөгерү күнекмәләрен үстерү. |
| | | “Бүре һәм сакрыклар” | Түгәрәккә басарга, күмәк уйнарга, хәрәкәтләрне дөрес итеп башкарырга күнектерүне дәвам итү. |
| | III | “Оядагы кошлар” | Сизгерлек, сигнал буенча хәрәкәт итү күнекмәләрен тәрбияләү. |
| | | “Үз парыңны тап” | Төрле юнәлештә йөгереп, сигнал булгач, үз парыңны табу күнекмәләрен үстерү, дус – тату уйнауны булдыруны дәвам итү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | IV | “Чүлмәк сатам” | Яшьтәшләре белән зур булмаган төркемнәрдә, үзләре белеп, татар халык уеннарын оештыруда мөстәкыйльлекләрен үстерү, уен кагыйдәсен үтәүне булдыру. |
| | | “Тизрәк түгәрәккә кер” | Музыканы игътибар белән тыңлау күнекмәләре булдыру, музыкка туктагач тәгәрәк эченә кереп басарга өйрәтү, җитезлек, хәрәкәт активлыгын формалаштыру. |
| февраль | I | “Машиналар һәм җәяүлеләр” | Юл йөрү кагыйдәләре турында белемнәрен ныгыту, тирә-якта ориентлашу күнекмәсен үстерү,игъбарлылык тәрбияләү. |
| | | “Кегляны аудар” | Төзлекне, тырыш, көчле, сәләтле, нык ихтыярлы булып үсүләренә этәргеч бирү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | II | “Төлке килә” | Сигнал буенча хәрәкәтләнү күнекмәләрен камилләштерү, сизгерлекләрен үстерү. |
| | | “Кыш бабай” | Сизгерлек, сигнал буенча хәрәкәт итү күнекмәләрен тәрбияләү. |
| | III | “Чаналар белән ярыш” | Җитезлекне, тизлекне булдыруны дәвам итү, дус –тату уйнау теләкләре тудыру. |
| | | “Соры бүре” | Күмәк уенда катнашасы килү теләге уяту, сак атлап йөрүче бүре образын хәрәкәтләр аша чагылдырырга омтылыш тудыру. |
| | IV | “Кошлар очалар” | Хәрәкәт тизлеген үстерүне дәвам итү, төрле юнәлештә очу күнегүләрен башкарып йөгерү, сигналларга игътибар итүне булдыру. |
| | | “Светофор” | Светофорның төсләре турындагы белемнәрен ныгыту, игътибарларын үстерү, уйлап эш итәргә өйрәтү. |
| март | I | “Кем әйберне тизрәк күчерә?” | Тизлек, сизгерлек үстерү, дус –тату уйнауны булдыруны дәвам итү,күрсәтелгән хәрәкәтләрне төгәл итеп башкарырга өйрәтүне дәвам итү. |
| | | “Тизрәк түгәрәккә кер” | Музыканы игътибар белән тыңлау күнекмәләре булдыру, музыкка туктагач тәгәрәк эченә кереп басарга өйрәтү, җитезлек, хәрәкәт активлыгын формалаштыру. |
| | II | “Инеш аша сикереп чык” | Урыннан 2 аякта ераклыкка сикерү күнекмәләрен камилләштерү, кыюлык тәрбияләү. |
| | | “Үрдәк атыш” | Тупны тотарга, туптан качарга өйрәтүне дәвам итү, төз атуны булдыру, балаларның хәрәкәтчәнлекләрен, җитезлекләрен үстерү. |
| | III | “Флагка кадәр сикер” | Сикерү күнекмәләрен үстерү, сыгынучанлык, чыдамлылык булдыру, бирелгән темп белән хәрәкәтләнергә өйрәтүне дәвам итү. |
| | | «Төсләр сату » | Йөгерү тизлеген үстерү, пространствода ориентлашу күнекмәләрен, төсләр турында белемнәрен камилләштерүне дәвам итү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | IV | “Үз парыңны тап” | Төрле юнәлештә йөгереп, сигнал булгач, үз парыңны табу күнекмәләрен үстерү, дус – тату уйнауны булдыруны дәвам итү. |
| | | “Миңлебай” | Яшьтәшләре белән зур булмаган төркемнәрдә, үзләре белеп, татар халык уеннарын оештыруда мөстәкыйльлекләрен үстерү, уен кагыйдәсен үтәүне булдыру. |
| апрель | I | “Бүре һәм сакрыклар” | Түгәрәккә басарга, күмәк уйнарга, хәрәкәтләрне дөрес итеп башкарырга күнектерүне дәвам итү. |
| | | “Тупны тәгәрәт” | Тупны предметлар аша тәгәрәтү, максатка ирешүчәнлек, башлаган эшне азагына кадәр эшләп чыгу күнекмәләрен үстерү. |
| | II | “Челән белән бакалар” | Сикерү тизлеген үстерү, сигнал буенча хәрәкәт итү, пространствода ориентлашу, тизлек булдыруны дәвам итү. |
| | | “Флагка кадәр йөгер” | Йөгерү тизлеген үстерүне дәвам итү, бер – бер артлы сигнал буенча йөгерү күнекмәләрен камилләштерү. |
| | III | “Тавык кетәклегендә төлке” | Җитезлек, өлгерлек тәрбияләү, тиз йөгерү, сикереп менү күнекмәләрен бирү өстендә эшне дәвам итү. |
| | | “Әбәк” | Игътибарлыкларын, хәтерен, кузаллауларын үстерү, рольләрне бүлешкәннән соң дөрес башкаруны булдыру, пространствода бәрелешмичә төрле юнәлештә йөгерү күнекмәләрен камилләштерү. |
| | IV | “Бал кортлары” | Йөгерү күнекмәләрен үстерүне дәвам итү, пространствода ориентлашуны камилләштерү. |
| | | “Куяннар” | Сикерү күнекмәләрен камилләштерү, уен барышында иптәше белән хәрәкәтләрне яраклаштырып башкару күнекмәсен үстерү. |
| май | I | “Беренче булып бас” | Игъбарлылык тәрбияләү, тырышлык, максатчанлык кебек яхшы сыйфатларны үстерү, физик активлыгын камилләштерү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | “Тупны, сикертеп, алып бар” | Тупны сикертеп алып барырга өйрәтә башлау, максатчанлык, батырлык сыйфатлары тәрбияләү. |
| | II | «Трамвай” | Игътибарлыкларын тупларга күнектерү, түземлек тәрбияләү, уен кагыйдәсен үтәргә өйрәтү. |
| | | “Буш урын” | Күзәтүчәнлекләрен, игътибарлыкларын үстерү, этешми-төртешми уйнау күнекмәләрен камилләштерү. |
| | III | “Чүлмәк сатам” | Яшьтәшләре белән зур булмаган төркемнәрдә, үзләре белеп, татар халык уеннарын оештыруда мөстәкыйльлекләрен үстерү, уен кагыйдәсен үтәүне булдыру. |
| | | “Очкычлар” | Төрле юнәлештә йөгерү күнекмәләрен системалаштыру, дус –тату уйнауны булдыру. |
| | IV | “Тизрәк түгәрәккә эченә кереп басарга | Музыканы игътибар белән тыңлау күнекмәләре булдыру, музыкка туктагач тәгәрәк кер” өйрәтү, җитезлек, хәрәкәт активлыгын формалаштыру. |

“Соры бүре” Күмәк уенда катнашасы килү теләге уяту, сак атлап йөрүче бүре образын хәрәкәтләр аша чагылдырырга омтылыш тудыру.

## 2.2. «СОЦИАЛЬ-ШӘХСИҮСЕШ» *Хезмәт*

***Аңлатма язуы***

«Хезмәт» белем бирү эшчәнлеге эчтәлеге балаларда хезмәткә уңай мөнәсәбәт формалаштыру максатын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели.

Татар халык әкиятләре ярдәмендә хезмәт эшчәнлеге турында күзаллаулар формалаштыру. Баланың эш барышын татар шагыйрьләренең хезмәт турындагы шигырьләре белән бәйләү.

Балаларга аңлаешлы һөнәрләр (төзүче, электрик, сантехник һ. б.) белән таныштыруны дәвам итү. Өлкәннәрнең хезмәт чичәнлегенең мәгънәсе турында күзаллаулар формалаштыруХезмәт эшчәнлегенең төп бурычы булып тора. Бу бурычны тормышка ашыру түбәндәге мәсьәләләрне чишү аша башкарыла:

- зурлар хезмәте белән танышу, хезмәтнең җәмкыятькә кирәклеге һәм файдасы турында күзаллауларын формалаштыруҺәм кеше хезмәтенә хөрмәт, хезмәтнең нәтиҗәсенә сак караш тәрбияләү;
- балаларның хезмәт эшчәнлеген оештыру, эш тәҗрибәсе , эшне оештыру, зурлар һәм яшьтәшләре белән үзара уңай мөнәсәбәтләр урнаштыру күнекмәләрен камилләштерү.

**_Комплекслы-тематик план_**

| **Тема** | **Интеграция** |
|---|---|
| ***Сентябрь*** | |
| 1. Үзлегенннән киенү – чишенү, киемнәрне шкафка тәртип белән җыеп кую күнекмәләрен формалаштыру.<br>2. Балаларны төркемдә һәм балалар бакчасы уен җирлегендә тәртип урнаштыру буенча кызыксындыру.<br>3. Үзлегеннән бүлмә һәм җирлек гөлләренә су сибү теләкләрен уяту.<br>4. Балаларның кул эшләренә теләкләрен уяту: тәрбиячегә китапларны һәм дидактик материалларны ремонтларга булышу. | *Уку:* профессияләр турында хикәяләр уку, шофёр профессиясе буенча рәсемнәр карау<br>*Аралашу:* балалар бакчасын6а азык – төлек алып килүче машиналарны күзәтү, күргәннәр буенча әңгәмә оештыру. |
| ***Октябрь*** | |
| 1. Үзлегенннән киенү – чишенү, киемнәрне шкафка тәртип белән җыеп кую күнекмәләрен камилләштерү.<br>2. Үзлегеннән төркемдә һәм балалар бакчасы уен җирлегендә тәртип урнаштыру күнекмәләрен өйрәнүне дәртләндерү.<br>3. Балаларда балалар бакчасы хезмәткәрләренә ярдәм итү теләкләрен уяту (урындыклар һәм өстәлләр өстеннән тузан сөртү, сөлгеләрне һәм урын – җир өстен алмаштырырга ярдәм итү).<br>4. Өстәлне иртәнге һәм көндезге ашка әзерләргә ярдәм итү теләкләрен формалаштыру (клакларны, чәнечкеләрне, стаканнарны кую).<br>5. Сюжетлы-рольле уен «Шофёр» | *Сәламәтлек:* үз – үзеңне тәртиптә тотарга кызыксындыру, шәхси гигиена таләпләрен үтәргә өйрәтү.<br>*Куркынычсызлык:* хезмәт кирәк – яракларыннан дөрес куллану һәм аларны дөрес урнаштыру күнекмәләрен фолмалаштиыру. |
| | |

| Ноябрь | |
|---|---|
| 1. Үзлегенннән киенү – чишенү, киемнәрне шкафка тәртип белән җыеп кую күнекмәләрен камилләштерү не дәвам итү, курчак киемнәрен юу һәм киптерергә өйрәтү.<br>2. Үзлегеннән төркемдә һәм балалар бакчасы уен җирлегендә тәртип урнаштыру күнекмәләрен өйрәнүне системалаштыру.<br>3. Балаларны бүлмә гөлләрен утырту һәм аларны тәрбияләү өстендә эшләүне тарту. | *Уку:* повар профессииясе турында хикәяләр уку, рәсемнәр карау.<br>*Аралашу:* балалар бакчасы кухнясына экскурсия, повар эшен күзәткәннән соң, хикәя төзергә өйрәтү.<br>*Социальләштерү:* кушылган эшкә карата җаваплылык формалаштыру . |
| **Декабрь** | |
| 1. Үзлегенннән киенү – чишенү, киемнәрне шкафка тәртип белән җыеп кую күнекмәләрен системалаштыру.<br>2.Үзлегеннән төркемдә һәм балалар бакчасы уен җирлегендә тәртип урнаштыру күнекмәләрен камилләштерү (сезонлы эш–җирлекне кардан арындыру) . 3. «Кухняда поварлар эше» дигән экскурсияне дәвам итү. | *Социальләштерү:* балаларны шәхси һәм тәркемләп кушылган эшләрне үтәргә тарту, бер – берсе арасында тәрбияче ярдәме белән эшне бүлергә өйрәтү.<br>*Уку:* зурлар хезмәтенең киршклеге турында хикәяләр уку, зурлар хезмәтен хөрмәт итү турында үрнәк китерү.<br>*Аралашу:* хезмәтнең җәмгыять, гаилә һәм балалар бакчасы өчен кирәклеге турында сөйләшү. |
| | |

| | |
|---|---|
| ***Январь*** | |
| 1. Балаларны һәр эштә, кыяфәттә җыйнак булырга теләк уяту, шәхси билгедә тәрбияләү.  кадәр эшләүне тәрбияләү, аны яхшы эшләүне<br>2. Зурлар ярдәме белән киемнәрне тәртиптә тоту күнекмәләрен формалаштыру (чистарту, киптерү). *Аралашу:* врач хезмәте буенча<br>3. Үзлегеннән зурларга ярдәм итү теләге уяту.  рәсемнәр карау, | *Социальләштерү:* башланган эшне азагына<br>булдыру.<br>сөйләшү,<br>теманы тикшерү теләге уяту. |
| ***Февраль*** | |
| 1. Үзлегеннән төркемдә һәм балалар бакчасы уен җирлегендә тәртип урнаштыру күнекмәләрен камилләштерүне дәвам итү (сезонлы эш – җирлекне кардан арындыру, сукмакларга песок чәчү) .<br>2. Оештырылган белем эшчәнлегенә кирәк яраклар әзерләү теләкләрен формалаштыру.<br>3. Балаларнытабигать почмагында орлыклар утыртырга, гулләрне күчерергә тарту.<br>4. Дидактик уен  «Әгәр куян авырса?» | *Куркынычсызлык:* карны күрәгәндә куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәүне формалаштыру.<br>*Танып белү:* табигатьпочмагындагы гөлләрнең һәм усемлекләрнеңисемнәрен белү. |
| ***Март*** | |
| 1. Үзлегеннән төркемдә һәм балалар бакчасы уен җирлегендә тәртип урнаштыру күнекмәләрен ныгыту.<br>2. Үзлегенннән киенү – чишенү, киемнәрне шкафка тәртип белән җыеп кую күнекмәләрен системалаштыруны дәвам итү.<br>3. Оештырылган белем эшчәнлегенә кирәк яраклар әзерләргә омтылыш тәрбияләү, деңурлык вазыйфаларын үтәүне булдыруны дәвам итү. | *Аралашу:* йорт хайваннарын караучы хезмәте турында сөйләшү. |

| Апрель | |
|---|---|
| 1.Дежур тору күнекмәләрен ныгыту, башланган эшне азагына кадәр эшләүне тәрбияләү .<br>2. Балалар бакчасы уен җирлегендә тәртип урнаштыру күнекмәләрен ныгыту (веранданы себерү, коелган ботакларны җыю).<br>3. Бакчада эшләүне булдыру. | *Уку:* С. Михалков«Почта», 1 өзеген ятлау.<br>*Аралашу:* балаларга почтальон (хат ташучы) хезмәте турында сөйләү. |
| **Май** | |
| 1.Үзеңә үзең хезмәт күрсәтү күнекмәләрен ныгыту.<br>2. Утырткан үсемлекләрне тәрҗияләүне дәвам итү.<br>3. Зурлар хезмәте турында (почтальон, врач, повар, шофер) белемнәрен камилләштерү.<br>4. Сюжетлы-рольле уеннар «Шофер», «Шифаханә» | *Аралашу:* үсемлекләрнең үсешен күзәтү, күргәннәр буенча сөйләшү.<br>*Социальләштерү:* уеннарда рольләрне дөрес башкаруны ныгыту. |

Белем өлкәсе “Социаль- шәхси үсеш” җәмгыятьтәге әхлак һәм әдәп кануннарын үзләштерүгә юнәлгән.

Планлаштыруинтеграция принциплары һәм төрле хезмәт һәм иҗат эшчәнлеге, көнкүрештәге куркынычсызлык кагыйдәләре формалаштыру буенча төзелгән ( ФГОС ДО).

***Куркынычсызлык***

***Аңлатма язуы***

«Куркынычсызлык» белем бирү эшчәнлеге эчтәлеге үз тормышыңның куркынычсызлыгы нигезләрен һәм экологик аң (әйләнә-тирә дөнья куркынычсызлыгы) алшартларын формалаштыру максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели.

***Тормыш куркынычсызлыгы нигезләрен формалаштыру***

Балаларны балалар бакчасында көндәлек режим һәм үз- үзләрен тотуның иң элементар кагыйдәләре белән, бүлмәдә хәвеф-хәтәрсез йөрү кагыйдәләре белән таныштыруны дәвам итү.

Үз тормышың куркынычсызлыгы нигезләре турында белемнәрне үзләштерү, саклык, сизгерлек хисе тәрбияләү. Кайчы, пычак, очлы предметлар белән эш итүдә, спорт инвентаре, пыяла предметлар кулланганда сак булырга күнектерү.

Балаларны тормышта яңа, алар өчен гадәти булмаган очракларда, таныш булмаган кешеләр белән очрашканда үз-үзләрен дөрес тотарга өйрәтү.

***Юлларда хәвеф-хәтәрсез йөрү тәртибе формалаштыру***

Юл хәрәкәтендә светофорның кызыл, сары, яшел төсләренең урнашу тәртибе һәм мәгънәләре белән таныштыру. Светофор сигналы буенча хәрәкәт итәргә күнектерү.

Балаларны юнәлешләрне (алга - артка, өскә - аска, уңга - сулга) аерырга гына түгел, шулай ук күрсәтелгән юнәлештә йөрергә, үзеңә карата теге яки бу әйбернең торышын (миннән сул якта - өй, уңда - машина, алда - җәяүлеләр, артта - велосипедчы) билгеләргә өйрәтү.

Чагыштырмача хәрәкәт итү тизлеген (тиз, акрын) билгеләргә, транспорт чараларының (трамвай, автобус, янгын сүндерү машинасы, ашыгыч ярдәм машинасы һ. б.ның) тавыш сигналларын аерырга, тавыш чыганагының кайда булуын сиземләргә, кирәк очракта туктарга өйрәтү. Ишетү-хәрәкәт координациясен үстерү.

Кайбер җәмәгать транспортлары (троллейбус, автобус, трамвай, поезд, самолёт, теплоход һ. б.) турында күзаллауларны баету; маршрут транспорты (автобус, троллейбус, трамвай) тукталышы урыннарын билгеләү; «Автобус яки троллейбус тукталышы»н аңлатучы билге белән таныштыру. Җәмәгать транспортына утыру һәм аннан чыгу кагыйдәләренә игътибар итү.

Балаларга метрополитен, тимер юл, поезд, машинист хезмәте, тимер юлда һәм тимер юл транспортында үз-үзеңне тоту кагыйдәләре турында сөйләү. Тимер юл макеты белән таныштыру.

Урамда үз-үзеңне тотуның иң элементар кагыйдәләрен (йөгермәү, кычкырмау, тротуар кырыеннан йөрмәү һ. б.) үтәүгә ирешү. Җәяүле юлы белән, «җәяүлеләр юлы» билгесе белән таныштыру; урамны кайда һәм ничек аркылы чыгу турында, велосипедта йөрү кагыйдәләре турында аңлату.

Уңга һәм сулга борылышлар ясап, түгәрәк буенча, предметларны әйләнеп үтеп, өч тәгәрмәчле велосипедта йөрергә өйрәтүне дәвам итү. Үз хәрәкәтләре белән идарә итә белү, тормозга басып туктата алу күнекмәләрен үстерү. Спорт мәйданчыгында иркен ориентлаша белүне камилләштерү.

Транспорт чараларының охшаш һәм аермалы якларын табарга, билгеләнгән үзлекләре һәм функциональ үзенчәлекләре буенча чагыштырырга һәм төркемнәргә берләштерергә өйрәтү, алынган мәгълүматны гомумиләштерергә тырышуларын («Охшашны җый», «Оча, йөзә, йөри» һ. б.) хуплау.

Өлкәннәр хезмәте турындагы белемнәрен киңәйтү: троллейбус (автобус) йөртүче троллейбус (автобус) йөртә; кар җыйгыч машинаны йөртүче юлларны кардан чистарта; ЮХИДИ инспекторы юлларда автомобильләр хәрәкәтен җайга сала һ. б.; эш төрләре һәм эш максаты арасында бәйләнешне ачыкларга ярдәм итү.

Балаларның, сюжетлы-рольле уенда юлда имин йөрү кагыйдәләрен чагылдыру өчен, мөстәкыйль рәвештә пред- метлы-уенлы мохит тудыруларын, модульләргә уен мәгънәсе бирүләрен, образлы һәм техник уенчыкларны, аларны алыштыручы алмаш предметларны куллануларын хуплау.

Балаларны уен ситуацияләрендә шартлы уйдырманың максатын аңларга, коллективта уен кагыйдәләренә яраклашып эш итәргә, игътибарлы булырга, уен персонажларының (транспорт йөртүчеләр, җәяүлеләр, пассажирлар һ. б.) роль буенча хәрәкәтләрен төгәлрәк башкарырга, ишетү һәм күрү сигналларына, әйләнә-тирәдәге көтелмәгән үзгәрешләргә тиз җавап бирергә, мөстәкыйльлек күрсәтергә һәм мәйданда ориентлашырга өйрәтү.

Мөстәкыйль дидактик уеннарда балаларның алган тәҗрибәләрен файдалануга шартлар тудыру. Төрле характердагы ял итү уеннары оештыру; юл йөрү кагыйдәләрен өйрәнү өчен әһәмиятле ситуацияләрне эченә алган уен-мавыгулар, курчак театры, сәхнәләштерелгән гади әсәрләр, уеннар өйрәнү.

Балаларда, шартлар буенча һәм үзләре уйлап тапканча, шәһәр (авыл) урамнары макетын төзү теләкләрен үстерү. Балаларны объектларның пространстводагы сурәтләмәләрен - озынлыкларын (биеклекләр, киңлекләрен) аера белү; деталь һәм аның өлешләренең урынын (өстән, астан, өстенә, астына һ. б.) билгеләүгә; объектларны (деталь һәм аның өлешләрен һ. б.ны) анализларга өйрәтү; тимер юллар, ике яклы хәрәкәт итү юллары, күперләр, гаражлар һ. б.төзүгә омтылышларын үстерү.

Балаларны табигать күренешләренә, тәүлектәге үзгәрешләргә һәм аларның әйләнә-тирәдә чагылышына (кич - урамда караңгы төшә - багана башларында фонарьлар яна, машиналар фараларын кабыза) игътибар итәргә өйрәтү. Юлларда куркынычсыз йөрү кагыйдәләрен өйрәнү процессына кызыксыну уяту.

***Экологик аң алшартларын формалаштыру***

Балаларны хайваннар белән очрашканда сак булырга өйрәтү, агулы үсемлекләрнең үзлекләре турында кисәтү. Кайбер куркыныч сыеклыклар, газсыман матдәләр, ут, зарарлы ашамлыклар турында, витаминнар, дару препаратларын күп күләмдә кабул итүнең куркынычлыгы турындагы күзаллауларын үстерү. ***Комплексы - тематик план***

| Ай | Атна | Тема | Бурычлар | Интеграция |
|---|---|---|---|---|
| сентябрь | I | Тема: «Светофор-безнең дус». Уен «Светофор маҗаралары» | Светофор , светофорның төсләре турында белемнәрен ныгыту. Машина юлындаһәм тротуарда үз-үзеңне тоту кагыйдәләре булән танышуны дәвам итү. Урам 2 өлешкә бүленгән икәнлеге турында белемнәрен үстерү. | *Иҗади сәнгать*: рәсем яки ябыштыру «Светофор». *Уку*: А. Усачев «Домик у перехода» (ятлау) *Социаль – коммуникатив үсеш*: фикер йөртү : «Берүзем өйдә», «Берүзем урамда», рәсемнәр буенча кечкенә хикәя төзү. *Физик культура*: хәрәкәтле уен «Төсле автомобильләр» |
| | II | Тема: «Өйдәге куркынычсызлык чыганаклары» | Балаларны көнкүреш предметлары белән таныштыру, аларның сәламәтлеккә зыян китерергә мөмкинлекләре турында аңлату. Көнкүрештәге куркынычсызлык кагыйдәләрен ныгыту. | |
| | III | Тема: «Ачык тәрәзәләр» | Балаларга ачык тәрәзәләрнең һәм балконнарның куркынычлык тудыру турында аңлату. Транспорт төрләре белән танышуны дәвам итү. | |
| | IV | Тема: «Алдакчы кыяфәт» | Балаларга таныш булмаган кешеләр куркыныч янавы турында аңлату. Таныш булмаган кешеләрнең җәберләүләре вакытында үз-үзеңне дөрес тоту турында өйрәтү. 01, 02,03 телефоннарыннан дөрес куллану турында сөйләшү. | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Октябрь | I | Тема: «Урам белән танышу» | Шәһәр урамнары турында күзаллауларын киңәйтү. | *Социаль – коммуникатив һәм танып белү үсеше:* урамга экскурсия. Уен “Дөрес – дөрес түгел». *Сөйләм үсеше:* имитацион уен «Юл аркылы ничек дөрес чыгарга». *Уку*: В. И. Мирясова шигырьләре *Иҗади сәнгать*: рәсем «Машиналар юлда». *Сәламәтлек*: иртәнге гимнастиканың, чыныктыруның, спорт белән шөгыльләнүнең файдасы турында сөйләшү «ЗОЖ» төшенчәсе кертү; һәлактләр булганда зурларга эндәшүнең кирәклеген аңлату “Зурлар безгә ярдәм итә” |
| | II | Тема: «Көтелмәгән очрашу» | Таныш булмаган балалар һәм яшүсмерләр белән аралашу кагыйдәләрен аңлату, 01,02,03 телефоннарын куллану кагыйдәләрен ныгыту. | |
| | III | Тема: «Юл йөрү билгеләре». *Дидактик уен* «Төс буеча сайла». *Имитацион уен* «Мин -шофер», *«Мин* - машина» | Юл йөрү билгеләренең әһәмияте турында өйрәтү. Юлда машина йөреше 2яклы булуын аңлату. «Җир асты юлы» билгесе белән таншышу. | |
| | IV | Тема: «Сәламәт буласың килсә...» | «Сәламәтлек төшенчәсе белән танышу». | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| ноябрь | I | Тема: «Светофорның 3 төсе». *Дидактик уен* «Җәяүлеләр һәм транспорт» | Светофорның төшенчәсетурында белемнәрен ныгытуюю. Җәяүлеләрнең юлда йөрү кагыйдәләре буенча белемнәрен формалаштыру. | *Танып белү һәм сөйләм үсеше*: Хикәя төзү «Юлда үзеңне ничек тотарга?” *Җыр*: музыкаль-дидактик уен «Урамны тыңлыйбыз». *Социальләштерү*: имитацион уен «Без автобуста». *Иҗади сәнгать*: ябыштыру «Минем машинага гараж». *Уку*: С. Маршак «Светофор» (ятлау). Танып белү: рәсем буенча кеше төзелешен карау |
| | II | Тема: «Шәһәр буенча сәяхәт». *Дидактик уен* «Юл йөрү кагыйдәләрен бел һәм үтә” | Шәһәрдә транспортта йөрү үзенчәлекләре белән танышу. | |
| | III | Тема: «Транспортта үзүзеңне дөрес тоту». Уен «Без барабыз, барабыз.....» | “Куркынычсызлык утравы” билгесе һәм әһәмияте белән таныштыру. Җәмгыять транспортыннда үзүзеңне дөрес тоту күнекмәләрен формалаштыруны дәвам итү. | |
| | IV | Тема: «Кешенең тән төзелеше» | Кешенең тән төзелеше турында таныштыру ( сулыш органнары, умыртка сөяге, ашказаны, кан әйләнеше) | |
| декабрь | I | Тема: «Айболит дәресләре» | «Вирус, микроб» төшенчәләре кертү. Чирләрдән котылу чаралары белән таныштыру, авырганда терелә чаралары турында сөйләшү. Чыныктыру һәм витаминнарның файдасын аңлату. | *Аралашу:*хикәя төзү«Безгә“Ашыгыч ярдәм" машинасы килә». |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | II | Тема: «Юлдагы ярдәмчеләр» | «Пешеходный переход», «Балалар» билгеләре турында белемнәрен камилләштерү. | *Уку:*К. Чуковский «Айболит» (уку һәм өзеген ятлау)<br>*Иҗади сәнгать: ябыштыру* «Безнең урамдагы автобус».<br>*Җыр:* имитацион уен«Мин машина».<br>*Уку:* А. Усачев«Дорожная песня»(ятлау) |
| | III | Тема: «Әдәп кагыйдәләре» | Балаларның транспортта йөрү кагыйдәләре турында белемнәрен ныгыту. | |
| | IV | Тема: «Җәяүлеләр һәм йөртүчеләр». *Сюжетлы – рольле уен*«Мин шофер» | Шофер хезмәтетранспорт төрләре, аларның йөреше белән таныштыруны дәвам итү. | |
| январь | I | Тема: «Сак бул, бозлавык!». | Кышкы юлның үзенчәлекләре белән таныштыру, куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәүне булдыру. | *Иҗади сәнгать:*рәсем «Юлда әни белән» һәм ябыштыру «Грузовик».<br>*Аралашу:* әңгәмә” Кышкы юлда һәм сулыкларда үзеңне тоту кагыйдәләре”, ПДД буенча табышмаклар үткәрү.<br>*Уку:* А. Дорохова «Зеленый, желтый, красный».<br>*Социальләштерү:* бармак |
| | II | Тема: «Кыш көне сулыклар» | Кыш көне сулыкларның үзенчәлекләре белән таныштыру, куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәүне булдыру. | |
| | III | Тема: «Юл йөрү билгеләре». *Дидактик уен* “Юл билгеләрен дөрес куй” | «Пешеходный переход», «Җир асты юлы» и «Сак бул: балалар» билгеләре белән таныштыруны дәвам итү. Машина юлы 2 яклы булырга мөмкин икенен искәртү. | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | IV | Тема: «Сак бул, бозлавык!» | Бозлы юлда сак йөрерүне кисәтү, егылган кешегә беренче ярдәм күрсәтергә тәкъдим итү. | театры«Светофор”, юлдагы машиналарны күзәтү *Хезмәт:* сукмакларга бозлавык вакытында песок сибү |
| февраль | I | Тема: «Мин җәяүле». *Уен* «Без юл аркылы чыгабыз» | Җәяүлеләрнең юлда йөрү кагыйдәләре белән таныштыруны дәвам итү. Юл билгеләре буенча белемнәрен камилләштерү. | *Иҗади сәнгать*:ябыштыру «Машинага тәгәрмәчләр». Уку: Т.Александрова «Светофорчик». Аралашу: «Мин югалсам...» дигән темага әңгәмә оештыру. *Физик культура*: «Нәрсә ул юл чаты?” дигән темага уеннар оештыру |
| | II | Тема: «Юл кырыендагы өй» | Светофорның үзенчәлекләре турында белемнәрен үстерү. Юл йөрү билгеләре турында күзаллауларын формалаштыруны дәвам итү. | |
| | III | Тема: «Йөртүчеләр һәм җәяүлеләр». *Сюжетлырольле уен* «Шофер» | Юлда билгеләргә карап ориентлашырга өйрәтү. Кышкы юлдагы машиналарны күзәтү. | |
| | IV | Тема: «Әгәр син урамда югалсаң» | Урамда югалсаң үз-үзеңне дөрес тоту кагыйдәләренең рәте белән таныштыру. | |
| март | I | Тема: «Сак бул, юл чаты!». *Уен* «Кем иң | Юл чатындагы юлда машиналарның йөрү тәртибе белән таныштыру. | *Иҗади сәнгать:* рәсем «Юл һәм тротуар»,ябыштыру «Минем яраткан транспорт төре». |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | укымышлы җәяүле?» | | *Уку:* В. Головко «Правила движения». *Аралашу:*әңгәмә «Ничек машиналар кешеләргә ярдәм |
| | II | Тема: «Транспорт төрләре». *Уен* | Юлда йөрүче машиналарны күзәтү, машина төрләрен истә калдыру | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | «Машиналар күргәзмәсе» | | итәләр» |
| | III | Тема: *Уен* «Кем иң яхшы җәяүле? | Балаларның юл йөрү билгеләре турында белемнәрен киңәйтү | |
| | IV | Тема: «Минем микрорайон» | Микрорайон макетында ориентлашырга өйрәтү. Практикада алган белемнәрне куллануны булдыру. | |
| апрель | I | Тема: «Урамда ятим хайваннар» | Урамда очраган ятим хайваннар белән үз-үзеңне дәрес тоту кагыйдәләрен өйрәнү. Балалар бакчасыннан өйгә кайту юлы турында сөйләшү | *Социаль – аралашу үсеше:* сюжетлы-рольле уен «Җәяүлеләр һәм йөртүчеләр» *Җыр:* күңел ачу «Балалар урманда». *Иҗади сәнгать:* төзү «Минем урам». *Аралашу:* әңгәмә «Велосипедта йөрим». *Уку:* |
| | II | Тема: «Безнең ярдәмчеләр». *Дидактик уен* «Сөйләшүче юл билгеләре» | Балалар бакчасыннан өйгә кайту юлы турында белемнәрен камилләштерү | |
| | III | Тема: «Урманда үзеңне ничек тотарга?» | Урманда үз-үзеңне дөрес тоту кагыйдәләре белән танышу, янгын чыганакларын кисәтергә өйрәтү. | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | IV | Тема: «Зарарлы үсемлекләр» | «Зарарлы үсемлекләр» төшенчәсе белән таныштыру, урманда үз-үзеңне дөрес тоту кагыйдәләре турында белемнәрен ныгыту. | В. Кожевников «Светофор». *Сәдамәтлек:* әңгәмә “Заралы үсемлекләр” |
| май | I | Тема: «Юлда җәяүле». *Дидактик уен* «Светофорны җый» | Алган белемнәрне кулланып юлда йөрү күнекмәләрен камилләштерү, светофор турында белемнәрен ныгыту | *Иҗади сәнгать: рәсем* «Мин балалар бакчасына барам»; күргәзмә оештыру «Үз кулларың белән ясалган светофор. *Физик культура:* хәрәкәтле уеннар “Төсле автомобильләр”, “Чыпчыклар һәм автомобиль” |
| | II | Тема: «Өйгә таба юл». *Дидактик уен* «Микрорайон | Микрорайон макеты буенча хәрәкәтләнү буенча белемнәрен киңәйтү. Өйгә кайту юлында тәртип кагыйдәләрен ныгыту | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | буенча сәяхәт» | | *Коммуникация: әңгәмә* “Без урамда уйныйбыз” |
| | III | Тема: «Мин юл йөрү кагыйдәләрен беләм» | Төрле юл ситуацияләреннән чыгу юлларын өйрәтү. | |
| | IV | Тема: «Юлда үз-үзеңне тоту кагыйдәләре». *Сюжетлы – рольле уен* «Йөртүчеләр һәм җәяүлеләр» | Юл йөрү билгеләре, юлда үз-үзләрен тоту кагыйдәләре турындагы белемнәрен ныгыту | |

***Социальләштерү***

***Аңлатма язуы***

«Социальләштерү» белем бирү эшчәнлеге эчтәлеге балаларның социаль характердагы беренчел күзаллауларын үзләштерү ьәм балаларны социаль мөнәсәбәтләр системасына кертү максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә нәм белем бирү бурычларын билгели.

Туган телдә аралашырга теләкләрен хуплау; башка кешеләр белән аралашканда, аларның тәкъдимнәренә әдәпле итеп җавап бирү; төрле эшчәнлек төрләрендә өлкәннәр һәм балалар белән телдән һәм телдән булмаган бәйләнешләр урнаштыру.

Әйләнә-тирә, туган шәһәр (авыл), республика вакыйгалары турында әңгәмәләрне хуплау.

Аралашу культурасы формалаштыру (сөйләшүченең милләтенә карап, ачык йөз күрсәтеп, шул телдә исәнләшү һәм саубуллашу; үтенеч һәм тәкъдимнәр белән ягымлы итеп мөрәҗәгать итү; күрсәткән хезмәте, ярдәме, сый-хөрмәте өчен рәхмәт белдерү).
Балаларны ил, республиканың күренекле төп бәйрәмнәрен билгеләп үтәргә өйрәтү. Балалар оешмасы, республика, ил тормышына баланың мөнәсәбәте, катнашы булуын аңлавына ирешү.
Өлкәннәр һәм яшьтәшләре (өч-дүрт бала) белән күмәк уеннарда катнашуга теләк уяту; әйләнә-тирәдәге тормыш, халыклар яшәеше темасына татар язучылары һәм шагыйрь¬ләренең әдәби әсәрләре, мультфильмнар буенча, уен өчен катлаулы булмаган сюжетлар тәкъдим итү.
Уендагы иптәшләр арасында рольләрне бүлә белергә, уен өчен кирәкле өй кирәк-ярагы (көянтә-чиләкләр, казан, уклау һ. б.), милли костюм, ювелир (зәркән) бизәнү әйберләре, читекләр һ. б., милли уенчыклар, музыка уен кораллары сайларга һәм аларны рольгә туры китереп файдаланырга өйрәтү.
Милли киемдәге курчакларны, образлы уенчыкларны, бибабо, кулдан ясалган уенчыклар һәм кайбер сәнгатьлелек чараларын, кул хәрәкәтләре, мимика, интонация кулланып, театральләштерелгән һәм режиссер уеннарында катлаулы булмаган сюжетлар буенча (татар халык әкиятләре буенча куелган мультфильмнардан) ситуацияләрне уйнап күрсәтү. Баланың үзе, әти-әнилөренең милләте турындагы күзаллавын формалаштыру. Гаилә рәсемнәрен караганда, әти-әниләре белән охшаш чалымнары булуына игътибар итү. Фото- сурәттәге кешеләрнең эмоциональ халәтен билгеләргә, аларның кәефләрен гаилә тормышындагы билгеле бер вакыйга белән бәйләргә өйрәтү.Гаилә турында һәм үзенең шул гаилә әгъзасы булуы турында; гаиләнең барлык әгъзаларының һәм баланың үзенең бурычлары, мавыгулары, яллары турында; гаилә гореф-гадәтләре, йолалары, бәйрәмнәренең матурлыгы һәм әһәмияте турында күзаллаулар формалаштыру. Гаилә истәлекләренә сакчыл караш тәрбияләү.

***Сюжетлы – ролле уеннар***

***Комплекслы – тематик план***

| **ай** | **атна** | **Эшчәнлек темасы** | **Эшчәнлек эчтәлеге** | **Бурычлар** |
|---|---|---|---|---|
| сентябрь | I | “Гаилә” | Әни кызын ашата, йокларга яткыра. Д./уен «Курчакны сыйлыйк», «Курчакны йокларга яткырыйк» | Рольләрне бүлешеп уйнарга өйрәнү, һөнәрләр һәм һөнәрләрнең эш |
| | | “Мин сатучы” | Әни кызы белән кибеткә килә, азык-төлек ала. Сатучы товар сата, үлчәүдә үлчи. | |
| | II | “Парковка” | Юлда машиналар йөри, юл йөрү кагыйдәләрен үтеп машиналарны урыннарга куялар. | кораллары турында белемнәрен үстерү,уйнаганда диалог коруны, татарча сөйләшүне булдыру. |
| | | “Коткару хезмәте” | Коткару хезмәте кешеләре авыр очракларда ярдәмгә ашыгалар: пожар, юлларда хәләкәт. | |
| | III | «Яшелчәләр кибете» | Әни кызы белән кибеткә килә, азык-төлек ала. Сатучы товар сата, үлчәүдә яшелчә үлчи.Д/уен “Яшелчә кибетендә ниләр сатыла”. | |
| | | «Көзге ярминкә» | Көзге ярминкәгә киләләр, яшелчә, җиләк-җимеш сатып алалар, хакларын очсызлаталар. | |
| | IV | “Даруханә” | Даруханәгә киләләр, нәрсә авыртканын әйтәләр, кирәкле дару сатып алалар. | |
| | | «Шифаханә» | Әни кызын врачка алып килә. Врач авыруларны кабул итә, нәрсә авыртканын сорый, тыңлый, дәвалау билгели. Медкабинетка экскурсия. | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| октябрь | I | «Гаилә» | Әни юа, кием үтүкли, бүлмә җыештыра. Д./уен «Курчакның күлмәген үтүклик, бездә тәртип» | |
| | II | «Балалар бакчасы» | Балалар бакчага килә, анда музыка, физкультура белән шөгыльләнәләр.Рәсемнәр карау. | |
| | III | «Гаилә» | Әни кызын ашата, йокларга яткыра, бишек җырлары җырлый. Уку: бишек җырлары. | |
| | IV | Транспорт» | Шофёр курчакларны машинага утыртып йөртә, төзү әйберләре ташый. Әңгәмә: “Машиналар урамда ничек йөри” | |
| ноябрь | I | Төзелеш» | Төзүчеләр машиналарга гараж төзиләр, уенчыкларга йорт, төзелеш коралларын кулланалар. Төзү материалларының детальларын карау. | |
| | II | «Йөртүчеләр һәм җәяүлеләр | Машиналар һәм җәяүлеләр юл йөрү билгеләрен үтәп эшкә баралар. Дидактик уен “Юл йөрү билгеләре” | |
| | III | «Чәчтараш» | Чәчтарашка балалар әниләре белән киләләр. Парикмахер чәч тарый һәм ала. Дидактик уен “Чәчтараш җиһазлары” | |
| | IV | «Гаилә» | Курчакның туган көне. Кунаклар чакырабыз, сыйлыйбыз. Әңгәмә «Бүген кемнең туган көне?» | |
| декабрь | I | «Кафе» | Кафега киләләр, алар туңдырма ашыйлар, сок эчәләр. Официант заказ кабул итә һәм сораган әйберләрне китерә. Дидактик уен «Без кафега килдек» | Рольләрне бүлешеп уйнарга өйрәнүне дәвам итү, балаларны уенчыклар белән сакчыл уйнарга өндәү,балаларны |
| | II | «Поликлиника» | Медсестра прививка ясый, витаминнар тәкъдим итә. Шәфкать туташы эшен күзәтү. | |
| | III | «Транспорт» | Балалар шәһәр буйлап экскурсиягә чыгалар, бәйрәмгә бизәлгән урамнарны карыйлар. Рәсемнәр карау. | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | IV | «Гаилә» | Әни кызы белән чыршы бизи, кунаклар каршы ала.Уку<br>О. Высотская «Ёлочка».<br>Дидактик уен «Акбайга кунаклар каршы алуны күрсәтик» | иптәшләренә карата кайгыртучан, игътибарлы, ярдәмчел булырга, кешелеклелек хисләре тәрбияләү. |
| январь | I | «Чәчтараш» | Чәчтарашка балалар әниләре белән киләләр. Парикмахер чәч тарый һәм ала. Дидактик уен “Чәчтараш җиһазлары” | |
| | II | «Шифаханә» | Кызы авыргач әнисе аны поликлиникага алып бара, врачка күрсәтә. Әңгәмә «Әгәр берәрсе авырса нишләргә” | |
| | III | “Театр” | Балалар театрга баралар, билетлар алалар, театр күрсәтәләр. Әңгәмә “Театр төрләре” | |
| | IV | «Транспорт» | Кунакка поездда баралар. Пассажирлар билет сатып алалар. Рәсемнәр карау. | |
| февраль | I | «Гаилә» | Курчакларны киендереп урамга чыгалар. Урамда балалар белән коляска йөртүче әниләрне күзәтәләр. Дидуен «Курчакны йөртәбез» | |
| | II | “Коткару хезмәте” | Коткару хезмәте кешеләре авыр очракларда ярдәмгә ашыгалар: пожар, юлларда хәләкәт, җир тетрәү. | |
| | III | “Машинаны төзәтәбез” | Машиналарны төзәтүче янына алып киләләр, төзәтүче машиналарны карый, төзәтә. | |
| | IV | “Автобус” | Балалар автобус тукталышында торалар, автобуска утыралар, билет алалар. Әңгәмә “Җәмгыять транспортында үзеңне тоту кагыйдәләре” | |
| мар | I | “Мин сатучы” | Әни кызы белән кибеткә килә, бәйрәмгә азык-төлек ала. Сатучы товар | Рольләрне |
| | | | сата, үлчәүдә үлчи. Әңгәмә “Сатучы һөнәре” | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | II | “Гаилә” | 8март бәйрәме: бүләкләр алу, үз кулларың белән әниләргә, әбиләргә бүләкләр ясау, өстәлне бәйрәмгә әзерләү.“Ләйлә шигырен уку, “Минем әнием” әңгәмә. | бүлешеп уйнау күнекмәләрен камилләштерү,балаларның дуслык турында мәгъләматларын тулыландыру, әләкләшүнең начар гадәт икәнен, дусларыңны уңайсыз хәлгә куярга ярамаганлыгын төшендерү. |
| | III | “Гаилә” | Курчакның киемнәрен юалар, үтәклиләр, киптерергә эләләр. Әңгәмә “Кием төрләре” | |
| | IV | «Цирк» | Балалар циркка баралар, билетлар алалар, клоуннар тамаша күрсәтә. | |
| апрель | I | “Янгын сүндерүчеләр” | Янгын сүндерүчеләр чакыруга килә, янгын сүндерә, беренче ярдәм күрсәтә, кисәтә. Дидактик уен “Азбука пожарных”, “Не играй с огнем”. Уку С. Маршак «Кошкин дом», «Пожар». | |
| | II | “Почта” | Кешеләр бер-берсенә хатлар язалар, телеграмма, посылка җибәрәләр. Почта ташучы аларны адреслар буенча тапшыра. Почтадан җибәрелгән әйберләрнең рәсемнәрен карау. Дидактик уеннар һәм күнегүләр: «Дустыма хат», «Минем адрес» | |
| | III | “Телефон салоны” | Балалар телефон салонына киләләр, телефоннар һәм фотоаппаратлар карыйлар, сатып алалар. Әңгәмә “Телефон ни өчен кирәк?” | |
| | IV | “Төзелеш” | Төзүчеләр киләләр, төзелеш өчен план алалар, күп машиналар өчен зур гараж, өйләр төзиләр, төзелеш объектларын тапшыралар.Рәсемнәр карау. Якын тирәдәге объектларны күзәтү. | |
| май | I | “Уенчыклар кибете” | Сатып алучылар уенчык сайлыйлар, сатучы белән киңәшәләр, кассага акча түлиләр, чекларны сатучыга бирәләр. Сатучы сатып алучылар белән әдәпле итеп сөйләшә, аларга төрле уенчыклар тәкъдим итә, аларның ни өчен яхшы булуын сөйли, уенчыкны бирә, сатып бирә. Әңгәмә “Әдәпле сатып алучылар”. Дидактик уен: «Уенчыкны тасвирла», «Нәрсә үзгәрде», «Тасвирлау буенча тап». | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | II | “Гаилә” | Җиңү бәйрәме: бүләкләр алу, үз кулларың белән бабайларга, әбиләргә бүләкләр ясау, өстәлне бәйрәмгә әзерләү. Әңгәмә “Җиңү бәйрәме” | Рольләрне бүлешеп уйнау күнекмәләрен ныгыту, |
| | III | “Транспорт” | Йөк һәм җидел машиналар урамда йөри, җәяүлеләр тротуардан | |
| | | | баралар, җәяүле чыгу урыныннан юл аркылы чыгалар, бетенесе дә юл йөрү кагыйдәләрен үтиләр.Светофорга, көйләнелми торган юл чатына максатлы сәяхәт.Дидактик уен: «Ихтибар, җәяүле», «Кызыл, сары, яшел» | һәнәрләрнең кирәк-яраклары турындагы белемнәрен үстерү, диалог корып сөйләшү күнекмәләрен камилләштерү. |
| | IV | “Кибет” | Төрле бүлекләре (табак-савыт, йорт җиһазлары, язу-сызу әйберләре h.б.) булган яңа супермаркет ачылды. Сатып алучылар әйбер сайлыйлар, сатучыдан алар турында сөйләвен сорыйлар ( төсе, материалы, кулланылышы. | |

## 2.3. «ТАНЫП БЕЛҮ ҮСЕШЕ» *Әйләнә*

***- ТИРӘ БЕЛӘН ТАНЫШУ***

***Аңлатма язуы***

«Танып белү үсеше» белем бирү эшчәнлеге эчтәлеге балаларда танып белү ихтыяҗларын һәм акылны үстерү максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели.

Баланы үзе яши торган урам, шәһәр (авыл), республика исемнәрен әйтергә өйрәтү. Шәһәрнең (авылның) истәлекле урыннары турында сөйләү.

Туган шәһәрдә (авылда) булган вакыйгалар турында әңгәмәләрдә ешрак катнашу тәҗрибәсе туплауларына ирешү. Туган як образлары белән бәйле буклетлар, журналлар, рәсемле китаплар, альбомнар, истәлекле урыннарда гаилә белән төшкән фотосурәтләр, значоклар, открыткалар җыелмасы тупларга теләк тудыру.

Кеше яши торган торак төзелеше (шәһәрдә һәм авылда), йорт кирәк-яраклары турында күзаллаулар булдыру. Кеше кулы белән ясалган җайланмаларның төзелеше һәм билгеләнеше турында сораулар бирергә, һәр яңалык белән танышырга омтылыш тәрбияләү.

Кешенең хуҗалык эшчәнлеген - үзе, тору урыны, йорт хайваннары һәм үсемлекләр, ишегалдының, урамының чисталыгын - кайгыртуы турында беренчел күзаллаулар формалаштыру. Шәһәр (авыл) урамнарын, торак йортларны тәртиптә тотарга теләк тудыру.

Бирелгән урынның кайбер үсемлекләре: агачлар (нарат, өрәңге), бүлмә гөлләре (бальзамин, фуксия), гөмбәләр (ак гөмбә, майлы гөмбә, баллы гөмбә), җимешләр (алма, слива), яшелчәләр (кыяр, помидор, суган, кишер, шалкан), җиләкләр (кура җиләге, миләш, чия, карлыган) белән таныштыруны дәвам итү. Өлкәннәргә җиләк-җимеш, яшелчәләр уңышын җыярга булышу теләге тудыру.

Бөҗәкләр (кырмыска, умарта корты, коңгыз, шөпшә) турындагы күзаллауларын баету; кыргый һәм йорт хайваннары, төркемдәге табигать почмагында яшәүчеләр белән танышуны дәвам итү. Балалар бакчасындагы участокка очып килүче кошларны (чыпчык, кызылтүш, песнәкне) күзәтү оештыру, аларны ел буена өстәмә ашатырга теләк уяту.

Балаларның кырда, урманда, елгада күргәннәрен сөйли алуларына ирешү. Үзләренә ошаган үсемлек, хайван, табигать почмагының рәсемен ясарга, фотога төшерергә омтылыш тәрбияләү

***Комплекслы – тематик план***

| ай | атна | Эшчәнлек темасы | Бурычлар |
|---|---|---|---|
| сентябрь | I | Көз безгә нәрсә алып килде? | Балаларның яшелчә һәм җиләк-җимеш турындагы белемнәрен тулыландыру; туган як табигатен, сезонлы үзгәрешләрне күзәтүдә әңгәмәгә тарту; хәтерне, игътибарлыкны, күзәтүчәнлекне үстерү; табигый витаминнарның кеше тормышындагы файдасы т-да кызыксыну, эстетик хисләр тәрбияләү.хисләре уяту. |
| | II | Урман үсемлек ләрен: гөмбәләр не һәм җиләк-җимешләрне күзәтү . | Гөмбәләрне һәм җиләк- җимешләрне тышкы кыяфәте буенча танырга, аерырга өйрәнү, сүзлек запасын баету, белемнәрен тирәнәйтү; балаларның ашарга яраклы һәм агулы гөмбәләр т-дагы белемнәрен камилләштерү; нинди булуларына карамастан(агулы яки ашарга яраклы ), урман үсемлекләрен сакларга кирәген аңлату. |
| | III | Кошларны күзәтү | Балаларның кошлар т-да белемнәрен ныгыту. тышкы билгеләренә, үз-үзләрен тотышларына карап кошларны аера белү күнекмәләрен үстерү; балаларда кошларга карата мәрхәмәтлелек, кайгыртучанлык хисе тәрбияләү. |
| | IV | Бөҗәкләрне күзәтү. | Балаларның бөҗәкләр т-гы белемнәрен арттыру, аларның яшәү рәвешләре, яшәү шартлары т-да күзаллауларын киңәйтү. балалларда уйлану, фикерләү сәләтен үстерү. балаларда барлык бөҗәкләргә карата мәрхәмәтлелек тәрбияләү, аларны рәнҗетмәскә кирәклеген төшендерү. |
| о к т | I | Экологик | Табигатьтәге үзгәрешләр турында белемнәрне ныгыту;экологик сукмактагы |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | сукмактан үтү | объектларны күрсәтү; табигатькә сакчыл караш тәрбияләү; табигать һәм кеше бәйләнеше турында башлангыч белемнәр бирү |
| | II | Йорт һәм кыр гый хайваннар турында белем нәрне ныгыту. (Дәфтәрләрдә эш) | Йорт һәм кыргый хайваннар, аларның яшәеше, көз көне нишләүләре турында белемнәрне ныгыту |
| | III | Декоратив кошлар - канарейка | Декоратив кошлар, аларның яшәеше турында башлангыч белем бирү, аларны тәрбияләргә омтылыш уяту |
| | IV | Кыргый хайван нар турында бе лемнәрне ныгы ту.(Дәфтәрләрдә эш) | Кыргый хайваннар, аларның яшәеше, көз көне нишләүләре турында белемнәрне камилләштерү |
| ноябрь | I | Көзге утырма. Өй хайваннары турында әңгәмә. | Балаларның сезонлы һәм табигатьтәге үзгәрешләр турындагы белемнәрен ныгыту; өй хайваннарының кышка әзерләнүе турындагы белемнәрен киңәйтергә. Өй хайваннарына карата кайгырту хисе формалаштыру. |
| | II | Кышлаучы һәм күчмә кошлар Дәфтәрләрдә эш) | Кошлар турында белемнәрне тирәнәйтү.<br>Кошларны танып белү күнекмәләрен ныгыту, табышмаклар өйрәнү.<br>Кошларга ярдәм итү теләге уяту |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | III | Тиздән кыш! Урманда кыргый хайваннар тормышы турында әңгәмә. | Балаларның кыргый хайваннарның кышкы тормышы турындагы белемнәрен тулыландыру. Тирә-яктагы табигатькә кызыксыну формалаштыру . Хайваннарга карата кайгыртучанлык мөнәсәбәте тәрбияләү. |
| | IV | Аквариум. | Балыклар турында өйрәнү, аларның күлдә һәм аквариумда яшәүләрен ачыклау. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Балыклар. Дәфтәрләрдә эш) | Балыклар һәм аларның ничек яшәүләрен белү теләге уяту |
| декабрь | I | “Кышкы табигать» | Кышкы табигатькә хас билгеләр турындагы белемнәрен үстерү, башка ел фасыллары белән чагыштыру, матурлыкка соклану хисе уяту. |
| | II | “Безгә Айболит килде” | Табип һөнәре белән таныштыру, кеше хезмәтенә хөрмәт уяту, балалар бакчасындагы табип кабинетына экскурсия оештыру |
| | III | “Кышкы урманга сәяхәт” | Кышкы табигатькә хас билгеләр турындагы белемнәрне ныгыту,җәнлекләрнең һәм кошларның кышка ничек җайлашуы турындагы белемнәрен арттыру, кышкы урманның матурлыгын күрергә өйрәтү, табигатькә сакчыл караш һәм мәхәббәт тәрбияләү. |
| | IV | «Яңа ел уенчыклары» | Балаларны Яңа ел бәйрәмен каршыларга әзерләү,чыршы уенчыклары белән таныштыру, пыяладан ясалган уенчыкларның, предметларның билгеләрен ачыклау; бал-ның сенсор сәләтләрен һәм кызыксынуын, күзәтүчәнлеген үстерү; чыршы уенчыкларына сак караш тәрбияләү. Бәйрәмгә карата кызыксыну уяту.Яңа ел бәйрәменә серлелек өстәү. |
| январь | I | “Минем гаилә” | Гаилә төшенчәсе турында белемнәрен үстерү, гаилә турында кечкенә хикәя төзү, балаларда зурларга һәм кечкенәләргә карата ихтирамлылык тәрбияләү. |
| | II | “Кыш билгеләре” | Бал-ның кыш турындагы белемнәрен ныгыту; балаларның күрсәтмә образлы фикерләвен үстерү; туган табигатькә мәхәббәт һәм эстетик хисләр тәрбияләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | III | “Җәнлекләркышкы урманда” | Балаларның кыргый хайваннар турындагы күзаллауларын формалаштыру, табигаттәге сезонлы үзгәрешләр турындагы белемнәрен ныгыту; бәйләнешле сөйләм телен үстерү, сөйләмнең грамматик төзелешен камилләштерү; хайваннарга сакчыл караш тәрбияләү. |
| | IV | “Кыш көне агачлар” | Кыш көне агачлардагы үзгәрешләрне билгеләү, чыршы күркәсен күзәтү. |
| февраль | I | “Йорт хайваннары” | Йорт хайваннары турында белемнәрен камилләштерү, песине һәм этне күзәтү, үзүзләрен тотышларын билгеләү |
| | II | “Юллар имин булсын” | Юлда үз-үзеңне дөрес тоту кагыйдәләрен кабатлау, ныгыту. |
| | III | «Үренте” | Балаларны чәчәк, суган үрентеләре утыртырга өйрәтү, урентеләрнең шытып чыгуын күзәтеп тору кирәклеген аңлату. |
| | IV | “Без – солдатлар!” | Балаларны Ватанны саклаучылар көне б/н таныштыру; очкычның, вертлетның өлешләрен, формасын аерырга һәм атарга өйрәтүне, исемнәрне сыйфатлар белән яраклаштыру күнекмәләре формалаштыруны дәвам итү; |
| март | I | ”Яз килә, яз!” | Балаларны яз, аның айлары, билгеләре турында белемнәрен ныгыту; табигать күренешләре турында күзалауларын формалаштыруны дәвам итү; табигатькә сак караш тәрбияләү. |
| | II | “Әнием турында сөйлим» | Бәйрәмнәр белән таныштыруны дәвам итү,әниләргә хөрмәт тәрбияләү. |
| | III | “Өй җиһазлары” | Балаларны өй җиһазлары белән таныштыруны дәвам итү, билгеле бер билгеләр буенча туплау. |
| | IV | “Язгы эшләр” | Балаларны яз, аның айлары, билгеләре турында белемнәрен ныгыту;яз көне башкарыла торган эшләр турында күзаллау формалаштыруны дәвам итү |

| | | | |
|---|---|---|---|
| апрель | I | “Табак – савытлар” | Табак – савытлар белән таныштыруны дәвам итү, билгеле бер билгеләре буенча бер төркемгә туплау |
| | II | “Мин яшәгән йорт” | Шәһәр урамнары белән таныштыруны дәвам итү, яшәгән адресларын белергә кирәклеген аңлату, туган якка карата мәхәббәт тәрбияләү. |
| | III | “Галәм киңлекләренә сәяхәт” | Беренче очучы Юрий Гагарин белән танышу аша илебезгә карата горулык хисләре тәрбияләү, образлы күзаллауларын үстерү,Кояш системасы, планеталар турында элементар белешмә бирү, алар турында күбрәк беләсе килү теләге уяту. |
| | IV | “Габдулла Тукай” | Балаларда Г.Тукайның күпкырлы иҗатына кызыксыну уяту,ихтирам хисләре тәрбияләү. |
| май | I | Тәҗрибә.Суның үзенчәлекләре | Яшәү чыганагы булган суга сак караш тәрбияләү.Гади тәҗрибәләр һәм уеннар аша балаларның су үзенчәлекләре турындагы белемнәрен тирәнәйтү. |
| | II | “Җиңү бәйрәме” | Җиңү көне турында күзаллауларын формалаштыру, кайбер хәрби һөнәрләр белән таныштыруны дәвам итү. Хәрбиләр һөнәренә хөрмәт, горурлык хисләре тәрбияләү. |
| | III | “Нәрсә ул- Кызыл китап?” | Балаларны сирәк очрый торган үсемлекләр турындагы китап б/н таныштыру.Китапка кертелгән хайван һәм үсемлекләрне кызгану,саклау хисләре тәрбияләү. |
| | IV | “Чәчәкләр” | Җәйге табигаттәге үзгәрешләр белән таныштыруны дәвам итү. Чәчәкләргә карата |
| | | | сакчыл караш тәрбияләү. |

## *ЭЛЕМЕНТАР МАТЕМАТИК ТӨШЕНЧӘЛӘР ФОРМАЛАШТЫРУ*

### *Аңлатма язуы*

Элементар математик төшенчәләр формалаштыру баланың акыл үсешендә зур урын алып тора. Оештырылган белем бирү эшчәнлегендә күп төрле дидактик уеннар кулланыла, логик мәсьәләләр чишелә.

Ел ахырына балалар алган белемнәр:

- предметларның характерлы билгеләрен аералар (төс, форма, зурлык);
- 5кә кадәр саный beləләр, барлыгы ничә? соравына җавап табалар;
- предметларны чагыштырып парларын табалар;
- 3-5 предметны бергә зурлыклары буенча чагыштыралар, үсү бару тәртибендә урнаштыралар;
- геометрик фигураларны һәм җисемнәрне аералар: өчпочмак, түгәрәк, квадрат, турыпочмаклык; шар, куб, цилиндр; аларның үзенчәлекләрен күрсәтә беләләр;
- пространствода һәм кәгазьдә ориентлаша алалар;
- уң һәм сул кулны аералар;
- тәүлек төшенчәсен аңлыйлар. ***Комплекслы – тематик план***

| МЕСЯЦ | 1 НЕДЕЛЯ | 2 НЕДЕЛЯ | 3 НЕДЕЛЯ | 4 НЕДЕЛЯ |
|---|---|---|---|---|
| СЕНТЯБРЬ | Один и много, сравнение множеств и установление соответствия между ними. Большой и маленький. Круг. Е.В.Колесникова,15 | Сравнение чисел 3 – 4 , счет по образцу, загадки. Времена года (осень). Слева, справа. Е.В.Колесникова,18 | Установление соответствия между числом и количеством предметов. Большой, поменьше, самый маленький. Квадрат. Развитие внимания. Е.В.Колесникова,20 | Счет по образцу, сравнение чисел 4 – 5. Части суток. Слева, в середине, справа. Е.В.Колесникова,22 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| ОКТЯБРЬ | Знакомство с цифрой 1. Слева, посередине, справа. Закрепление знаний о круге, квадрате. Е.В.Колесникова,25 | Закрепить знания о цифре 1. Большой, поменьше, маленький. Треугольник. Е.В.Колесникова,26 | Знакомство с цифрой 2. Вчера, сегодня, завтра. Ближе, дальше. Е.В.Колесникова,28 | Закрепить знания о цифре 2. Короткий, длинный. Овал. Е.В.Колесникова,30 |
| НОЯБРЬ | Знакомство с цифрой 3. Соответствие цифры с количеством предметов. Времена года (осень). Е.В.Колесникова,32 | Закрепление знаний о цифрах 1,2,3. Высокий, низкий. Развитие внимания. Е.В.Колесникова,34 | Соответствие количества предметов с цифрой. Сравнение чисел 3 – 4. Широкий, узкий. Прямоугольник. Е.В.Колесникова,36 | Счет по образцу, сравнение смежных чисел. Развитие внимания. Круг, овал. Е.В.Колесникова,38 |
| ДЕКАБРЬ | Знакомство с цифрой 4. Большой, поменьше, самый маленький. Развитие внимания. Е.В.Колесникова,40 | Закрепление знаний о цифрах 1, 2, 3, 4. Влево, вправо. Е.В.Колесникова,42 | Закрепление знаний о цифрах 1, 2, 3, 4. Счет по образцу, сравнение смежных чисел. Далеко, близко. Е.В.Колесникова,43 | Соответствие цифры с количеством предметов. Вверху, внизу, справа, под. Квадрат, прямоугольник. Времена года. Е.В.Колесникова,45 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| ЯНВАРЬ | | Знакомство с цифрой 5. Слева, посередине, справа. Е.В.Колесникова,47 | Закрепление знаний о цифре 5, сравнение чисел 4 – 5. Соответствие формы предметов с геометрическими фигурами. Быстро, медленно. Е.В.Колесникова,49 | Знакомство с порядковыми числительными. Верхний правый угол, нижний правый угол, верхний угол, нижний левый угол, середина. Е.В.Колесникова,51 |
| ФЕВРАЛЬ | Закреплений знаний о порядковом счете. Сравнение знакомых предметов с геометрическими фигурами. Большой, поменьше, самый маленький. Е.В.Колесникова,53 | Зависимость числа от величины предметов. Порядковый счет. Установление последовательности событий (части суток). Широкий, поуже, еще поуже, самый узкий. Е.В.Колесникова,55 | Счет по образцу. Закрепление знаний о цифрах 1, 2, 3, 4, 5, соответствие цифры с числом. Вечер, сегодня, завтра. Шар, куб, цилиндр. Е.В.Колесникова,57 | Закрепление знаний о порядковых числительных. Закрепление знаний о круге, квадрате, треугольнике, овале, Прямоугольнике. Е.В.Колесникова,60 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| МАРТ | Установление соответствия между цифрой и количеством предметов. Слева, посередине, справа. Развитие внимания. Е.В.Колесникова,62 | Закрепление знаний о порядковых числительных. Счет по образцу. Влево, вправо. Установление последовательности событий. Е.В.Колесникова,64 | Независимость числа от пространственного расположения предметов. Математические загадки. Развитие глазомера. Развитие внимания. Е.В.Колесникова,66 | Закрепление знаний о порядковом счете. Определять пространственное расположение предметов по отношению к себе. Развитие внимания. Е.В.Колесникова,67 |
| АПРЕЛЬ | Счет по образцу. Числа и цифры 1, 2, 3, 4, 5. Соответствие количества предметов с цифрой. Развитие внимания. Е.В.Колесникова,69 | Закрепление знаний о цифрах 1, 2, 3, 4, 5. Порядковый счет. Слева, справа, вверху, внизу. Е.В.Колесникова,70 | Соответствие количества предметов с цифрой. Счет по образцу. Сравнение реальных предметов с геометрическими телами. Развитие внимания. Е.В.Колесникова,72 | Соответствие количества предметов с цифрой. Математическая загадка. Слева, справа. Развитие внимания. Е.В.Колесникова,74 |
| МАЙ | Математическая загадка. Закрепление знаний о цифрах. Широкий, узкий. Времена года. Е.В.Колесникова,76 | | | |

## 2.4. «СӨЙЛӘМ ҮСЕШЕ»

### *МАТУР ӘДӘБИЯТ БЕЛӘН ТАНЫШУ*

### *Аңлатма язуы*

«Матур әдәбият уку» белем бирү эшчәнлеге эчтәлеге балаларда китап укуга кызыксыну һәм ихтыяҗ формалаштыру максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели.

Әдәби әсәрләрнең төрле жанр һәм тематикасын - халык әкияте, татар язучылары һәм шагыйрьләренең хикәя, шигырьләрен, шигъри фольклорның кече формаларын тыңлау, аларның эчтәлегенә хисләрен белдерү сәләтен үстерү.

Әкият геройлары һәм аларның характерлары, чынбарлыкта булган хәлләр, балалар һәм өлкәннәр эшләгән эшләр турындагы күзаллаулар ярдәмендә баланың эчке дөньясын баету, укыганны аңлар өчен сораулар бирү һәм фикер алышу.

Тәрбияче ярдәмендә татар әкиятләреннән өзекләрне сәхнәләштерергә өйрәтү.

Укыган әсәрдән аеруча кызыклы, сәнгатьле өзекләрне кабатлаганда, балаларга сүзләрне һәм катлаулы булмаган фразаларны әйтеп бетерергә мөмкинлек бирү.

Кечкенә күләмле шигырьләрне, шигъри фольклорның кече формаларын яттан сөйләүләрен хуплау. Уен
һәм сәнгать эшчәнлекләрен, конструкцияләү һ. б. ны әдәби образлар белән баету.

### *Комплекслы – тематик план*

| Вакыты | Жанры | Әсәрләр | Максат |
|---|---|---|---|
| Сентябр | Халык авыз иҗаты | **Җырлар, юаткычлар, эндәшләр, бармак уеннары.** « Кояшкаем, чык, чык...», «Кәк күк, кәк-күк...», «Әтисенә ай кебек...», «Бас, кызым Әпипә...», «Баш бармак, балан ияк...» | Татар халкының мәкаль - әйтемнәре белән таныштыру, яттан өйрәнү |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | **Әкиятләр.** «Хәйләгә каршы хәйлә»; «Ата каз»; «Калач». | |
| | Әкиятләр һәм легендалар<br><br>Дөнья халыклары әкиятләре | «Икмәк», төрекмән халык әкияте;<br><br>«Комсызлык бәласе», венгр халык әкияте. | Халык әкиятләре белән таныштыруны дәвам итү, аларда дөреслек- ялган, яманлык – кешелеклелек, гаделлек – намуссызлык һәм башка сыйфатлар берсе икенчесенә каршы куелуын, тормышта тискәреләр, сараннар, наданнарның көлке хәлгә төшүләрен аңлату. |
| | Шигърият | **Шигърият.** Г. Тукай. «Күз»;<br>Л. Лерон. «Яфрак бәйрәме»;<br>М. Хөсәен. «Пескәем»; Я.Игәнәй. «Чебиләр сөенделәр»; Б.Рәхмәт. «Бакчага килгәч»;<br>З.Туфайлова.«Аның өчен оялам»;<br>Ә. Бикчәнтәева.«Минем әнием»;<br>Р. Бәшәр. «Светофор»;<br>Р. Вәлиева. «Уяталар»;<br>Р. Харис. «Юмартлар». | Сәнгатьле уку, сөйләү күнекмәләрен ныгыту, укыганны аңлау күнекмәләрен ныгыту, укыган буенча фикер алышырга өйрәтү; укыгынны кабатлап сөйләү күнекмәләрен үстерү; әсәрнең жанрын билгеләргә өйрәтү, персонажларның хәленә керә белергә өйрәтү, текстны рольләргә бүлеп уку, әсәрләрне сәхнәләштерү күнекмәләрен булдыру |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Чәчмә әсәрләр | Ә. Хәсәнов.«Балалар бакчасында»;<br>Г. Гомәр. «Чуар тавык»;<br>Г. Вәлиева. «Дуслык күпере»; Л.Толстой. «Зирәк чәүкә»;<br>В. Осеева. «Начарлык»;<br>К. Ушинский. «Хайваннар бәхәсе», «Тавык һәм үрдәкләр»;<br>А. Әхмәт. «Минеке, тимә!» | Укыганны аңлау күнекмәләрен ныгыту, укыган буенча фикер алышырга өйрәтү; укыгынны кабатлап сөйләү күнекмәләрен үстерү; әсәрнең жанрын билгеләргә өйрәтү, персонажларның хәленә керә белергә өйрәтү, текстны рольләргә бүлеп уку, әсәрләрне сәхнәләштерү |
| | Әдәби әкиятләр | Хәйдәр. «Керпе туны»; | |

-

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Батулла. «Аю Әппәс»; | күнекмәләрен булдыру |
| | Яттан өйрәнү өчен шигырләр | К. Нәҗми. «Көз»;<br>Г. Тукай. «Елның дүрт фасылы» (Көз);<br>Җ. Тәрҗеманов. «Йомшак су, йөгерек су»;<br>«Кояш, чык, болыт, кач...», татар халык авыз иҗаты. | Шигырьне аңлап яттан сөйләү күнекмәләрен ныгыту; татар шигырьләренә кызыксынучанлык тәрбияләү; хәтерне яхшырту; сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен камилләштерү |

| Вакыты | Жанры | Әсәрләр | Максат |
|---|---|---|---|
| **Декабрь. Январь, февраль** | Җырлар, такмаклар, тел көрмәкләндергечләр | «Чума үрдәк, чума каз...»;<br>«Әй чулпысы, чулпысы...»; «Болыт, болыт, килмә син...»; «Әби коймак пешерә». | Татар халкының мәкаль - әйтемнәре белән таныштыру, яттан өйрәнү |
| | Әкиятләр һәм легендалар<br><br>Дөнья халыклары әкиятләре | «Ике ялкау»; «Ябалак»; «Балыкчы аю».<br><br>«Төлке белән Аю», мари халык әкияте, Р. Вәлиев тәрж.;<br>«Бөдрә чәчле кыз», чукот халык әкияте, Р. Вәлиев тәрҗемәсе. | Халык әкиятләре белән таныштыруны дәвам итү, аларда дөреслек- ялган, яманлык – кешелеклелек, гаделлек – намуссызлык һәм башка сыйфатлар берсе икенчесенә каршы куелуын, тормышта тискәреләр, сараннар, наданнарның көлке хәлгә төшүләрен аңлату. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Шигърият | Ә. Кари. «Кыш»;<br>Г. Толымбай. «Буран»;<br>Н. Мадьяров. «Шуабыз»;<br>Ә. Кари. «Тиен»; «Кошлар туйдырам»;<br>Р. Корбан. «Оекбаш»;<br>Б. Рәхмәт. «Уенчыклар»;<br>Н. Гайсин. «Гөлсия»;<br>М. Садри. «Һаҗирә апа»;<br>Ә. Бикчәнтәева. «Кыш бабай килгән»; | Сәнгатьле уку, сөйләү күнекмәләрен ныгыту, укыганны аңлау күнекмәләрен ныгыту, укыган буенча фикер алышырга өйрәтү; укыгынны кабатлап сөйләү күнекмәләрен үстерү; әсәрнең жанрын билгеләргә өйрәтү, персонажларның хәленә керә белергә өйрәтү, текстны рольләргә бүлеп уку, әсәрләрне сәхнәләштерү күнекмәләрен булдыру |
| | | К. Булатова. «Солдатлар»;<br>Р. Миңнуллин. «Туган илнең улы мин». | |
| | Чәчмә әсәрләр | Ә. Бикчәнтәева. «Тәмле сүз»;<br>М. Әмир. «Бәби әйтә»;<br>3. Хөснияр. «Куян кучтәнәче, яки Телсез малай»;<br>М. Гафури. «Әби белән онык»; | Укыганны аңлау күнекмәләрен ныгыту, укыган буенча фикер алышырга өйрәтү; укыгынны кабатлап сөйләү күнекмәләрен үстерү; әсәрнең жанрын билгеләргә өйрәтү, персонажларның хәленә керә белергә өйрәтү, текстны рольләргә бүлеп уку, әсәрләрне сәхнәләштерү күнекмәләрен булдыру |
| | Әдәби әкиятләр | А. Алиш. «Бикбатыр белән Биккуркак»; А. Толстой. «Төлке белән Кысла», Ә. Еники тәрҗемәсе. | |
| | Яттан өйрәнү өчен шигырләр | «Ак калач»;<br>Г. Тукай. «Елның дүрт фасылы» (Кыш);<br>Җ. Тәрҗеманов. «Кыш»;<br>М. Фәйзуллина. «Кыш бабай». | Шигырьне аңлап яттан сөйләү күнекмәләрен ныгыту; татар шигырьләренә кызыксынучанлык тәрбияләү; хәтерне яхшырту; сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен камилләштерү |

| Вакыты | Жанры | Әсәрләр | Максат |
|---|---|---|---|
| **Март, апрель, май** | Халык авыз иҗаты | «Бас, кызым, эзенә...»; «Ай, диләр, вай, диләр...»; «Карга килер — казан асар...»; «Ябалак, ябалак...»; «Камка түти, оч, оч...» | Татар халкының мәкаль - әйтемнәре белән таныштыру, яттан өйрәнү |
| | Әкиятләр һәм легендалар<br><br>Дөнья халыклары әкиятләре | «Тавык, Тычкан һәм Көртлек», «Карт белән Төлке», «Торна белән Төлке». «Конфет ашап тамак туямы?», корея халык әкияте, Р. Вәлиев тәрж.; «Тавык белән Сарык», болгар халык әкияте, Р. Гариф тәрж.; «Күбәләкләр ничек | Халык әкиятләре белән таныштыруны дәвам итү, аларда дөреслек- ялган, яманлык – кешелеклелек, гаделлек – намуссызлык һәм башка сыйфатлар берсе икенчесенә каршы куелуын, тормышта тискәреләр, сараннар, наданнарның көлке |
| | | килеп чыккан?», филиппин халык әкияте; «Әтәч һәм Бөркет», тибет халык әкияте; «Кәҗә бәтие, Бәрән һәм Бозау», абхаз халык әкияте. | хәлгә төшүләрен аңлату. |

| | | |
|---|---|---|
| Шигърият | Г. Тукай. «Елның дүрт фасылы» (Җәй);<br>С.Сөләйманова.«Әниләр бәйрәме»;<br>Ф. Кәрим. «Яз җитә»;<br>Н. Гайсин. «Яз килә»;<br>Ә. Бикчәнтәева. «Сыерчыклар»; Х. Халиков. «Хәерле иртә»;<br>Ш. Галиев. «Тыныч йокы»;<br>З. Туфайлова. «Нәни ташчылар»;<br>Л. Лерон. «Светофор — тәмле тамак». | Сәнгатьле уку, сөйләү күнекмәләрен ныгыту, укыганны аңлау күнекмәләрен ныгыту, укыган буенча фикер алышырга өйрәтү; укыгынны кабатлап сөйләү күнекмәләрен үстерү; әсәрнең жанрын билгеләргә өйрәтү, персонажларның хәленә керә белергә өйрәтү, текстны рольләргә бүлеп уку, әсәрләрне сәхнәләштерү күнекмәләрен булдыру |
| Чәчмә әсәрләр | А. Алиш. «Эшче абый»;<br>С. Сәүбәнова. «Шифалы сөт»;<br>Ф. Садриев. «Ботка»;<br>В. Осеева. «Бер әби»;<br>Татар халык мәзәге «Көйсез бала»;<br>Ф. Зыятдинов. «Бип-бип»; Л. Толстой. «Җимеш төше»;<br>Г. Гатауллин. «Керпе». | Укыганны аңлау күнекмәләрен ныгыту, укыган буенча фикер алышырга өйрәтү; укыгынны кабатлап сөйләү күнекмәләрен үстерү; әсәрнең жанрын билгеләргә өйрәтү, персонажларның хәленә керә белергә өйрәтү, текстны рольләргә бүлеп уку, әсәрләрне сәхнәләштерү күнекмәләрен булдыру |
| Әдәби әкиятләр | Р. Вәлиева. «Кыңгырау чәчәк»; Ә. Гаффар. «Койрык»;<br>Батулла. «Шапшакларны бака ялый»; К. Ушинский. «Куян белән Керпе».<br>В. Бирюков. «Мактанчык песи баласы»; | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Яттан өйрәнү өчен шигырләр | Татар халык авыз иҗаты «Мияу-мияу, мин качам...»; Р. Вәлиева. «Яз»; | Шигырьне аңлап яттан сөйләү күнекмәләрен ныгыту; татар шигырьләренә кызыксынучанлык |
| | | Ш.Галиев. «Дәү әнигә күчтәнәч»; Ә. Рәшит. «Кояшлы ил». | тәрбияләү; хәтерне яхшырту; сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен камилләштерү |

***СӨЙЛӘМ ТЕЛЕН ҮСТЕРҮ***

***Аңлатма язуы***

Балада туган теленә карата кызыксыну уяту. Уен ситуацияләре, мәгълүмати-аралашу технологияләре куллану, балалар эшчәнлегенең төрле төрләрен (уен, аралашу, нәтиҗәле эшчәнлек төрләрен) оештыру аша сөйләмне аңлау һәм туган телдә сөйләшәсе килү теләге уяту.

Туган телендә аралашуны үзләштерү өчен шартлар булдыру. Авазларны дөрес әйтү, сәнгатьле сөйләм нигезләрен формалаштыру.

## *Комплекслы – тематик план*

| Сроклар | Бүлекләр | Тема | Бурычлар |
|---|---|---|---|
| **20.08.10.09.** | **Белем бәйрәме** | Безнең уенчыклар | 1) балаларда предметларны тасвирлау; вак моториканы камилләштерү; исем, сыйфат кулланып, гади җөмләләр төзергә |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | өйрәтү, предметлар атамасы, аларның өлешләрен атау, нинди материалдан ясалуы турында сөйләү хисабына сөйләмнәрен активлаштыру; "ш" авазын ныгыту; |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | 2) балаларның кызыксынучанлыгын, игътибарын, хәтерен, фикерләвен үстерү;<br>3) балаларда уенчыкларга карата сакчыл караш, дустанә үзара мөнәсәбәт тәрбияләү. |
| **11.09.30.09.** | **Көз** | "Песи балалары белән" дигән сюжетлы картина карау | 1) балаларның көзге турындагы үзгәрешләр белемнәрен сюжетлы ныгыту; персонажларын игътибар карау; эчтәлек картина буенча белән җавап бирү; сорауларга элементларын иҗадилык күрсәтү осталыгын формалаштыру, песи һәм аның балалары исемнәрен сөйләмдә куллану, җәнлекләр |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | гамәлен билгеләүче сүзләр хисабына сүзлек запасын баету һәм активлаштыру;<br>2) балаларның игътибарын, кабул итүләрен,хәтерен, сенсор сәләтләрен, уен кагыйдәләрен үтәү теләген үстерү;<br>3) песиләргә карата сакчыл мөнәсәбәт, кайгыртучанлык тәрбияләү. |
| **1.10.-20.10.** | **Мин - дөньяның бер кешесе** | Гаилә | 1) балаларда, гаилә әгъзасы буларак, үзләре турында күзаллаулар формалаштыру; кеше тормышында гаиләнең әһәмиятен күрсәтү;<br>2) үзләренең гаилә әгъзалары турында сөйләү осталыгын, кабул итүләрен, игътибарын, хәтерен үстерү; сөйләмнең грамматик төзелешен камилләштерү, сүзлекне ныгыту;<br>3) гаилә әгъзаларына карата хөрмәт, ярату, горурлык хисләре, ихтирам тәрбияләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **21.10.04.11.** | **Минем шәһәрем, минем Ватаным** | Синең куркынычсызлыгың -синең кулларда | 1) балаларны куркынычсызлык кагыйдәләре белән таныштыру; тротуар, юлны аркылы чыгу урыны, машина юлы, куркынычсызлык каешы, регулировщик кебек яңа сүзләр һәм сүзтезмәләр хисабына сүзлек байлыгын үстерү; туган як, шәһәр турында, транспорт төрләре турындагы белемнәрен ныгыту;<br>2) балаларның кызыксынуын, игътибарын, хәтерен, фикерләвен үстерү;<br>3) балаларда дустанә мөнәсәбәт, ярдәмләшү хисе тәрбияләү. |
| **15.11.31.12.** | **Яңа ел бәйрәме** | Кыш бабай турында хикәя төзү | 1) әләре (схема) буенч күнекмәләре төзү ләре белән иректе аралашыр; балаларны тәрбия -<br>2) игътибарны, а өйрәтүне дәвам игү; фантазияне, сөйләмдә еш кулланыла торган исемнәрне, сыйфатларны, фигыльләрне куллану; күмәк эшләү осталыгы үстерү;<br>3) Яңа елга карата кызыксыну тәрбияләү. |
| | | | |
| | | Әкияти җәнлекләрнең кышкы маҗаралары | 1) тәрбияченең сүзле буенча күрсәтмәләре (схема) осталыгын күмәк хикәя төзү хайваннарны формалаштыру; |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | тасвирлаганда хаталарны табуда күнектерү; 2) игътибарны, конкрет-образлы фикерләүне, сөйләмне, күмәк эшләү осталыгын үстерү; 3) Яңа елга карата кызыксыну, хайваннарга карата сакчыл |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | мөнәсәбәт тәрбияләү. |
| | | Чыршыкай купшыкай | 1) Яңа ел бәйрәме, турында чыршы күзаллаулар формалаштыруны дәвам итү; 2) сөйләмнең грамматик төзелешен камилләштерү, хикәя төзү осталыгын, кабул итүләрен, хәтерен, игътибарын, бармаклар моторикасын үстерү; 3) күтәренке кәеф атмосферасы тудыру. |
| **01.01.31.01.** | **Кыш** | Ап-ак тунлы кыш | 1) балаларның кыш турындагы белемнәрен киңәйтү; танып белү һәм эзләнүгә омтылыш формалаштыру; "аста", "өстә", |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | "төбендә" һәм эшчәнлектә кулланган башка фразалар, чагыштыру сыйфатлары хисабына сүзлек байлыгын активлаштыру; "у" авазын ныгыту; 2) балаларның игътибарын, хәтерен, фикерләвен, бәйләнешле сөйләм телен үстерү; 3) балаларда кызыксыну, эшләү хисләре бердәм тәрбияләү. |
| | | Кыргый хайваннар | 1) кыргый җәнлекләр турында күзаллаулар формалаштыруны дәвам итү; 2) сөйләмнең грамматик төзелешен камилләштерү; хикәя төзү осталыгын, игътибарын, кабул итүләрен үстерү; 3) кыргый хайваннарга карата кызыксыну уяту. |
| **01.02.23.02.** | **Ватанны саклаучылар көне** | Хәрби һөнәрләр | 1) балаларның хәрби һөнәрләр һәм аларның төрләре, танк турындагы белемнәрен |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | формалаштыру; исем, сыйфат кулланып, гади җөмләләр төзергә өйрәтү;<br>2) балаларның кызыксынуын, игътибарын, хәтерен, хәрәкәтен, фикерләвен үстерү;<br>3) балаларда хәрби һөнәрләргә хөрмәт тәрбияләү. |
| | | Очучылар | 1) балаларны очкычның (самолетның) өлешләрен, зурлыгын, формасын аерырга һәм атарга өйрәтүне, исемнәрне сыйфатлар белән яраклаштыру күнекмәләре формалаш тыруны, [у] сузык авазын әйтүдә күнектерүне дәвам итү;<br>2) балаларның нинди? кайда? кая? нәрсә? сорауларына тулы фразалар белән җавап бирү осталыгын, игътибарын, танып белүләрен, кызыксынуын үстерү;<br>3) төрле гаскәр төрләренә, очучы һөнәренә хөрмәт, патриотлык хисләре тәрбияләү |
| | | Иң яхшы әти (Йомгакла у чарасы) | 1) сәнгать әсәрләре балаларның аша сөйләм культурасын, татар халкының әдәби әсәрләрен белү теләген формалаштыру; сөйләм |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | нормаларын үзләштерү;<br>2) татар җыр-биюләренә соклану, алар белән кызыксыну теләкләрен үстерү;<br>3) ана телендә аралашырга теләк уяту; үз гаиләң, эти-әниең белән горурлану хисе тәрбияләү. |
| **24.02.08.03.** | **8 Март** | Әниләр бәйрәме | 1) балаларның турындагы әниләр бәйрәме мәгълүматларын киңәйтү; әниләр турында тасвирлау хикәясе сөйләргә өйрәтү; 2) балаларның игътибарын, кабул |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | итүләрен,хәтерләрен, фотография кулланып, эзлекле сөйләүләрен үстерү;<br>3) әниләргә мәхәббәт һәм аларга ярдәм итү теләге тәрбияләү. |
| | | "Эт көчекләре белән" дигән картина буенча хикәя төзү | 1) сюжетлы картинаның персонажларын игътибар белән карау; эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирү; тәрбияче белән бергә сөйләү осталыгын формалаштыру; эчтәлекне сөйләгәндә, иҗадилык элементларын куллануга ярдәм итү; сөйләмне сыйфатл ар куллану хисабына баету;<br>2) балаларның игътибарын, хәтерен, күрү осталыгын, тыңлау танып белүләрен, |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | кызыксынуларын үстерү; карата<br>3) йорт хайваннарына кайгыртучанлык тәрбияләү. |
| **09.03.-**<br>**20.03.** | **Халык җәүһәр-ләре** | Бияләй һәм перчатка | 1) татар в<br>халкының кул<br>эшләребелән ;рга җавап бирергә өйрәтүне дә<br>таныштыру; культураны,<br>тәрбияченең сөйләмнең<br>сөйләмен аңларга,<br>сораул кул ам итү;<br>2) сенсор кызыксыну, тырышлык, сүзлек<br>байлыгын, грамматик<br>төзелешен үстерү;<br>3) халкыбызның эшләре<br>белән пөхтәлек, сакчыл чисталык,<br>караш тәрбияләү. киемнәргә |
| **01.04.-**<br>**20.04.** | **Яз** | Аюның язгы маҗаралары | 1) балаларны исем, сыйфат кулланып гади җөмләләр төзергә өйрәтү; язның төп билгеләрен<br>ныгыту; бирелгән сүзләргә антонимнар сайлауны форм<br>балаларның сүзлек запасын киңәйтү;<br>2) балаларның ıксынуын,<br>игътибарын, хәтерен, үстерү; ›икерләвен |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | 3) балаларда табигатькә сакчыл<br>караш, дустанә тәрбияләү. мөнәсәбәт |
| | | Урман күлендә | **1**) балаларның [с], [з], [у], [ш]<br>авазларын дөрес әйтүләрен |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | ныгыту, [ж] авазының артикуляциясен исләренә төшерү, бу авазны сүзләрдә, фразаларда әйтүдә күнектерү; язның төп билгеләре, айлары, табигать күренешләре турындагы белемнәрен ныгыту; балаларның сүзлек запасын киңәйтү;<br>2) балаларның кызыксынуын, ишетү игътибарын, хәтерен, логик фикерләвен, вак моторикасын үстерү;<br>3) балаларда табигатькә сакчыл караш, мөнәсәбәт дустанә тәрбияләү. |
| **21.04.09.05.** | **Җиңү бәйрәме** | Транспорт | 1) балаларны транспорт белән таныштыруны дәвам итү; төрләре төренә карап, аларны классификацияләргә, бер транспорт төре турында тасвирлау хикәясе төзергә |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | өйрәтү; Җиңү көне уңаеннан транспорт турындагы күзаллауларын формалаштыруны дәвам итү; 2) балаларның диалоглы сөйләмен, конкрет-образлы фикерләвен, классификацияләү осталыгын, игътибарын, кызыксынуын, сүзлек запасын үстерү; 3) ветераннарга карата хөрмәт, горурлану хисләре һәм |
| | | | коллективта эшләү уңай теләге уяту; атмосфера тудыру. |

## 2.5. «ИҖАДИ - ЭСТЕТИК ҮСЕШ»

***СӘНГАТЬ ИҖАДЫ***

***Аңлатма язуы***

«Иҗади сәнгать» белем бирү эшчәнлеге эчтәлеге балаларда әйләнә-тирәдәге матурлыкка кызыксыну уятуны һәм үз-үзләрен күрсәтү ихтыяҗларын канәгатьләндерүне формалаштыру максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели.

### *Рәсем ясау*

Балаларның игътибарын табигать матурлыгына юнәлдерү, алар белән берлектә үсемлек һәм хайваннар дөньясы объектларының форма, төс, төзелеш камиллегенә соклану.

Татар декоратив-гамәли сәнгате әсәрләре белән танышуны дәвам итү.

Балаларны «орнамент» төшенчәсе белән таныштыру. Татар орнаментында оста итеп чагылдырылган чын чәчәкүсемлек мотивларын карау. Бизәкнең өлешләрен аера белергә өйрәтү.

Балаларны декоратив эшчәнлеккә тарту: өч яфрак (бер ноктадан өч тапкыр буяу), күкчәчәк, ромашка (акчәчәк), миләш, гөлҗимеш һ. б. ны ясау ысулларын күрсәтү.

Бер, ике яки берничә төсне кулланып, гади элементлардан торган тасма (бордюр) бизәге ясый белүне формалаштыру. Чәчәкле үсемлекләргә төсләрне туры китерү кирәклегенә игътибар итү.

Берничә өлештән (кош, күбәләк, умарта корты фигуралары) торган предметларның формасын һәм төзелешен чагылдырырга өйрәтү.

Төсмерләр (зәңгәрсу, соры, алсу, шәмәхә) белән таныштыру, төсләрне тою хисен үстерү.

Татар декоратив-гамәли сәнгате үрнәкләре буенча күмәк эшләрне үтәүгә тарту.

Туган шәһәр (авыл) тормышыннан матур вакыйгаларны рәсемгә төшерергә теләк уяту. Рәсемнәрне бергәләп карау һәм нәрсә ясаганны сөйләүләренә ирешү. Иҗади активлык тудырырга булышу.

### *Ябыштыру*

Кисеп ябыштыру сәнгатенә кызыксыну уяту, аның эчтәлеген катлауландыра һәм төрле сурәтләү мөмкинлекләрен киңәйтә бару.

Туры сызык буенча башта кыска, аннары озынрак тасмалар кисәргә өйрәтү. Төсле кәгазьдән киселгән тасмалардан предмет сурәтләргә өйрәтү. Сирень, артыш чәһәкләреннән торган композиция төзү өчен, өзек-өзек аппликация техникасы белән таныштыру.

Чәчәкләр, җиләк-җимешләр һ. б. ны ясау өчен, квадраттан түгәрәкләр һәм турыпочмаклыктан оваллар кисәргә күнектерү. Бизәү максатыннан полосада, квадрат, түгәрәктә декоратив бизәкләр төшерергә өйрәтү. Ритм-тоемлау хисен уяту.

Бер бит кәгазьдә берничә предметны кисеп ябыштыру юлы белән (урам, шәһәр), балаларны сюжетлы аппликация төзүгә якын китерү. Пөхтә эшләү күнекмәләре булдыру.

Татар декоратив-гамәли сәнгатенең үрнәкләре буенча әзер формалардан (чәчәкләр, күбәләкләр, кошлар) коллектив композиция төзегәндә, үзара ярдәмләшеп эшләү теләге уяту.

***Әвәләү***

Әвәләп ясау белән кызыксынуны үстерү; балчыктан (тозлы камыр, пластилин) әвәләү күнекмәсен камилләштерү.

Зур кисәктән кечерәк кисәкләр өзеп яки чеметеп алу, аларны бармаклар ярдәмендә түгәрәкләп тәгәрәтү, өлешләрне тоташтыру (чәчәк, гранат, миләш җимешләре); янчелгән шарның өстен шомарту, җиңел генә тарттырып, кырыйларын чеметкәләп чыгу - бөрү (гөбәдия, вак бәлеш һ. б.) күнекмәләре формалаштыру. Махсус таякчык (стека) ярдәмендә ике яки дүрт кисәккә бүлеп (бәлеш кисәкләре), килеп чыккан формаларны үзгәртергә тырышуларын хуплау.

Яңа форма барлыкка китерү өчен, шарның уртасын яньчеп, чокыр ясау ысулын куллану. Махсус таякчыкны файдалану ысуллары белән таныштыру. Әвәләп ясалган әйберләргә шушы таякчык ярдәмендә милли бизәкләр төшерергә омтылуларын хуплау.

Балчык (тозлы камыр, пластилин) белән пөхтә итеп эшләргә күнектерү.

Әвәләп ясалган әйберләрне күмәк композициягә (тәлинкәдәге сый, чәй сервизы һ. б.) берләштерү. Уртак эш нәтиҗәсен күреп шатлану хисләре уяту. Декоратив әвәләп ясауда халык уенчыклары үрнәкләре (Шәмәрдән, Актүбә һ. б. уенчыклар) буенча иң гади образлар тудырырга теләк уяту.

Өстәл театрында куллану өчен, татар халык әкиятләре буенча сюжет әвәләп ясауга кызыксыну һәм теләк тудыру. Балаларда өлкәннәр белән уртак эш нәтиҗәләрен күреп шатлану хисләре уяту.

***Комплекслы – тематик план***

***Рәсем***

| Ай | **Эшчәнлек темасы** | **Бурычлар** |
|---|---|---|
| сентярь | “ Безнен шкафчикларга рәсемнәр” | Максат:Балаларны шкафтагы рәсемнен мәгънәсен билгеләргә өйрәтергә. Балалар үзләре иҗат итсен өчен аларга унайлыклар ясарга. Предметнын картинасын ясарга һәм башка бүлмәләрнен төзелешен белергә. |
| | “Тәрәзәгә карыйк” | Балаларны гади сюжет буенча рәсем ясарга өйрәтергә. Сюжет сайлауда яңа ысуллар белән таныштырырга. |

| | | |
|---|---|---|
| | | Апликатив рамалар ясар өчен шарт тудырырга. Үзләренен әйләнә-тирәсенә кызыксыну тәрбияләнергә. |
| | “Батыр этәч” | Балаларны гуашь буяулары белән этәч ясарга өйрәтү, форма һәм төсләрне дөрес туры китерү. Пумаланы мускулларны киеренкеләндермичә һәм бармакларны кысмыйча, дөрес итеп тотарга өйрәтүне дәвам итү; пумала белән буяу күнекмәләрен камилләштерү.Үрнәк буенча эшләү күнекмәләрен үстерү. |

| | | |
|---|---|---|
| октябрь | “Алма - кызыл, баллы” | Балаларны гуашь буяулары белән төрле төстәге алма ясарга өйрәтү. Контурга кермичә буяуны ныгыту, рәсемне тулы биткә урнаштыру күнекмәләре булдыру. Балаларга эстетик тәрбия бирү. |
| ноябрь | “Тычкан һәм чыпчык” | Балаларны әкиятләр сюжетлары буенча рәсем ясарга өйрәтү. Үрнәк буенча эшләү күнекмәләрен үстерү. Балаларга эстетик тәрбия бирү |
| | “Ак куян соры булган” | Балаларны куянның сурәте үзгәрүе бн таныштыру. Эксперементаль эш өчен шартлар тудыру. Уйлап табу эшчәнлегенә ышаныч һәм инициатива тәрбияләү. |
| декабрь | “Кар кызы” | Тун кигән кар кызын сурәтләргә өйрәтү (җилкәдән туны аска таба киңәеп киткән); пумала һәм буяу белән рәсемләүне ныгыту, тунның буявы кипкәч кенә бизәкләрне төшерергә күнектерү. |
| | “Яңа ел белән котлау открыткалары” | Мөстәкыйль рәвештә рәсемнең эчтәлеген уйлап чыгарырга һәм уйлаганны рәсемдә күрсәтергә өйрәтү;рәсем ясауның техник алымнарын ныгыту(буяуларны дөрес куллану, пумала юарга һәм киптерегә күнектерү). Балаларның эстетик тойгыларын,фантазияләрен үстерү, мөстәкыйльлек тәрбияләү |
| гыйнвар | “Минем яраткан уенчыгым” | Балаларны рәсемнәренең эчтәлеген уйлап ясарга, өлешләренең формаларын күрсәтеп ясарга өйрәтү.Буяулар белән эшли белүләрен ныгыту, мөстәкыйльлек тәрбияләү, ясаган рәсемнәре турында сөйли белүләренә ирешү. |
| | “Яулыкка бизәк төшерү(дымка | Дымка уенчыгы һәа аның бизәкләре белән танышу. Бизәкләрнең элементларын аерырга (туры кисешкән юллар, нокталар) өйрәтү. |
| | бизәге)” | |

| | | |
|---|---|---|
| февраль | “Тармаклы агач” | Агач сурәтен ясаган вакытта аның юан һәм нечкә ботакларын карандашны каты һәм әкрен басып ясарга өйрәтү; яхшы нәтиҗәләргә ирешергә күнектерү, иҗадилыкны үстерү. |
| | “Матур кошчык” | Түгәрәк һәм овал формаларын берләштереп кошчык ясарга өйрәтү. Аның томшыгын, тәриләрен ясау алымнарын аңлату, чиста эшләү күнекмәләрен бирү |
| март | “Матур чәчәкләр атты” | Балаларны төрле формалар китереп чыгара торган хәрәкәтләр белән матур чәчәкләр ясарга өйрәтү; балаларда эстетик тойгылар үстерү, төсләрне уйлап сайлап алырга күнектерү; матурлыкны күрә белергә өйрәтү. |
| | “Курчакның күлмәген бизәү” | Балаларны таныш элементлардан (сызыклар, ноктадар, түгәрәкләр)бизәкләр төзергә өйрәтү. Бизәкләрне ясаган вакытта һәр бизәккә пумала белән эшләүнең үз алымын куллану. Балаларда иҗадилык, эстетик тойгылыр, күзаллауларын үстеру |
| апрель | “Әкияттәге теремкәй” | Балаларны рәсемдә әкият образын чагылдырырга өйрәтү. Образлы күзаллауны, теремкәйне бизәгәндә мөстәкыйльлек һәм иҗадилык үстерү. Бизәүнең төрле алымнарын кулланырга күнектерү. |
| | “Минем яраткан курчагым” | Рәсемдә яраткан уенчыкларның образын ясарга өйрәтү; ясаган рәсемнәрне карап иң матур рәсемне сайлый белү һәм ни өчен ул рәсем матур икәнлеген аңлату. Формаларны дөрес күрсәтә белүне, кеше фигурасының өлешләрен дөрес урнаштыруны аңлату. Бөтен битне тутурып ясарга өйрәтүне дәвам итү. |
| май | “Самолетлар оча” | Карандашка төрлечә басып, болытлар аша очкан самолетларны рәсемдә ясарга өйрәтү. Образлы күзаллауны үстерү. Ясаган рәсемнәренә карата эмоциональ һәм уңайлы тойгылырны уяту. |
| | “Бәйрәмчә бизәлгән йорт” | Рәсемнең эчтәлеген уйларга өйрәтү. Иҗадилыкны, үзлегеннән эшләүне тәрбияләү. |

***Комплекслы – тематик план***

***Ябыштыру***

| ай | Эшчәнлек темасы | Бурычлар |
|---|---|---|
| сентябрь | Поезд бара ”тук “тук” “ тук” | Максат: Балаларны качы тотарга һәм туры кисәргә өйрәтергә:турыпочмаклыкны тар буйчыкларга кисәргә.<br>Күз белән кулнын бергә әшен үстерергә.<br>Җыйнаклылык тәрбияләргә,коралны өйрәнергә кызыксуну тудырырга. |
| | Чәчәклек | Максат: Балаларны кәгәзь формалардан төсе һәм формасы килерлек итеп чәчәк ясарга өйрәтергә.<br>Чәчәк төзү ысулларын күрсәтергә, кәгәзь форманы кул белән кисәргә,кечкенә форманы зуррагына ябыштырырга өйрәтергә. |

| | | |
|---|---|---|
| октябрь | Көзге яфраклар. | Максат: Балаларны табигый материал--- кипкән яфраклардан композицион сюжет ясарга өйрәтү..<br>Композиция һәм төс күнекмәләрен үстерү.<br>Клей белән пөхтә файдалана белүне ныгыту.<br>Үз эшеңне күреп сөенә белү хисе тәрбияләү.. |
| | Алтын көнбагыш. | Максат: Балаларны төрле материалдан матур көнбагыш чәчәге ясарга өйрәтү. Чәчәк төзү ысулларын күрсәтергә, кәгәзь форманы кул белән кисәргә,кечкенә форманы зуррагына ябыштырырга өйрәтергә.<br>Эстетик зәвык тәрбияләү. |
| ноябрь | Тема: Болытлар күк буйлап йөгерделәр... Аппликациямозаика рәсем элементлары белән | Максат: балаларны мозаика сыман кисеп ябыштыру техникасы б-н таныштыру, болыт контурына зәңгәр, соры, зәңгәркүк һәм ак кәгазьләрне тар буйчыклар итеп кисеп ябыштырырга өйрәтү |

| | | |
|---|---|---|
| | “Яулык бизәү» | Балаларны туры сызык буенча озынча полоскалар кисәргә, кайчы белән сак эш итәргәгә, яулык очларын матур итеп бизәргә өйрәтү. Әниләргә карата хәрмәт тәрбияләү. |
| декабрь | “Уенчык салынган арба” | Турыпочмаклыкның, квадратның почмакларын түгәрәкләп кисеп алуны ныгыту. Иҗат итәргә балаларда теләк уяту. |
| | “Чыршыга төймәләр” | Балаларны түгәрәк формалар кисә белергә күнектерү. Кайчы белән эшли белүне ныгыту. Матурлыкка соклану, бәйрәм хисе тәрбияләү. |

| | | |
|---|---|---|
| январь | “Матур пирамидалар” | Балаларны квадрат, түгәрәк формалар кисә белергә күнектерү. Кайчы белән эшли белүне ныгыту. Кирәкле төсләрне сайлап алырга һәм иң зур түгәрәктән кечкенә түгәрәккә түгәрәкләрне урнаштырырга өйрәтү. |
| | “Автобус” | Турыпочмаклыкның почмакларын түгәрәкләп кисәргә өйрәтү, полоскадан кечкенә квадратлар кисеп алуны ныгыту (автобусның тәрәзәләре). |
| февраль | “Алъяпкычка бизәк төшерү” | Квадраттан өчпочмаклар, түгәрәкләр кисеп алуны күнектерү. Чиста матур ябыштырырга өйрәтү, төсләр балкышын дөрес сайлау, үз эшеңнән кәнагатләнү хисе алу. |
| | “Күктә самолетлар оча” | Коллектив эштә бергә сөйләшеп эшләргә өйрәтү, рәсемне тулыландырырга өйрәтүне дәвам итү |
| март | “Әнигә бүләк” | Балаларга квадраттан почмакларын түгәрәкләп кисәргә өйрәтүне дәвам итү. Эстетик зәвык булдыру, кул чукларының моторикасын ныгыту. Кайчыны дөрес тотарга, сак эш итәргә өйрәтү. |
| | “Курчакларга чокыр бизибез” | Балаларны матур төсләр кулланып, матурлап бизәргә, бизәкләр кисәргә өйрәтү, кайчыны дөрес тотып сак эш итәргә өйрәтүне дәвам итү; турыпочмактан, квадраттан түгәрәкләр кисүне күнектерү, пөхтә кләйләү алымнарын ныгыту. Матурлыкны күрә һәм тудыра белергә өйрәтү. |
| апрель | “Ракета” | Турыпочмаклыкны икегә бөкләп почмакларын кисеп алырга өйрәтү. Альбом битендә ракетаны диагональ буенча урнаштыру, чиста итеп эшли белергә өйрәтү,эшкә кызыксыну уяту. |
| | “Кис һәм нәрсә ябыштырасың килсә, шуны | Үз эшләренең эчтәлегеен уйларга, эшләргә өйрәтү. Кәгазьдән турыпочмак, түгәрәк, квадрат формалары кисү. Иҗадилыкны тәрбияләү. |
| | эшлә” | |

| | | |
|---|---|---|
| май | “Кызыл калфак” | Аппликациягә әкият образы бирергә өйрәтү. Кешене сурәтләргә( күлмәк формасы, баш, аяк, кул,) өйрәтүне дәвам итү.Пөхтә кисәргә һәм ябыштыра алуны ныгыту. |
| | Тылсымлы бакча. | Коллектив композиция булдыру; кайчы белән турыга, квадратның, турыпочмакның почмакларын түгәрәкләп кисүне өйрәтүне дәвам итү. |

***Комплекслы – тематик план***

***Әвәләү***

| ай | Эшчәнлек темасы | Бурычлар |
|---|---|---|
| сентябрь | Әнә безнен поезд бара, тәгәрмәчләр шакылтый | Максат: Балаларны паравоздан һәм вагоннардан коллектив композиция төзергә өйрәтергә. Пластилинны тигез кисәкләргә бүлергә өйрәтергә. |
| | Чәчәклектә бөҗәкләр | Максат: Балаларны формасын китереп бөҗәкләр ябыштырып ясарга өйрәтергә. Мөстәкыйльлек һәм пөхтәлек тәрбияләргә. |
| октябрь | Карбыз. | Максат: Балаларны зурлыгы һәм формасы буенча туры китереп карбыз телеме (кабыгы, төше, эче) ясарга өйрәтү.<br>Пластилинны тигез кисәкләргә бүлергә өйрәтергә. |
| | Мухомор. | Максат: Балаларны дүрт өлештән торган мухомор әвәләргә өйрәтү.Эшләпәсе, аскы өлешләрен чеметеп чыгару юлы белән ясарга өйрәтүне дәвам итү,изәргә,бөгеп эшләргә өйрәтү..<br>Үрнәк буенча эшләүгә теләк уяту. |

| | | |
|---|---|---|
| ноябрь | Түтәл кәбестә һәм кишер белән | Максат: Кишер белән кәбестәне ничек ябыштыруны өйрәтергә, холык үзенчелеге белән формасына тапшырып.Төрле яшелчәлерне бер ысул белән генә ябыштырып күрсәтергә. Табигатьнең яхшы белгән күренешләрең матуркларын белешергә.<br>Сүзлек эше: түтәл, сабакъяфрак |
| | Меңә Керпе – башсыз, аяксыз. | Максат: Балаларны өйрәтергә керпене ничек ябыштырырга, аның тышны күрелешләренә һәм холкы үзенчелегенә игьтибар биреп. Форманы сизем белән, фикер йөртү, сәләтен һәм композициясен үстерү. Уйлап табу эшчәнлегенү ышаныч һәм инициатива тәрбияләү. |

| | | |
|---|---|---|
| | Шигырь эчтәлеге буенча сюжетлы әвәләү: Себер мәчесе аягын ялый. | Максат: Йоклаган мәчене конструктив ысул белән әвәләү һәм аны батареяда урнаштыру (пластилин кисәгендә). Мәче сыйфатларын санау, аларга ягымлы караш тәрбияләү. |
| декабрь | Кар бабайлар әвәлибез. | Төрле зурлыктагы түгәрәкләрне әвәләргә өйрәтү; әвәләү алымнарын ныгыту; эстетик зәвык формаларын тоюны үстерү. |
| | “Теләк буенча әвәләү” | Балаларны үз теләкләре буенча мөстәкыйль һәм иҗади рәвештә уйлаган нәрсәләрен ясарга өйрәтү. Әвәләүнең төрле ысулларын кулланып эшләүне ныгыту. |
| | “Кар кызы” | Балаларны кеше фигурасы әвәләргә өйрәтүне дәвам итү. «Озынча-багана формасы», «түгәрәк-шар»формаларын әйтә белергә өйрәтү.Шөгылгә карата балаларда кызыксыну уяту. |
| | “Яңа елга кучтәнәч” | Балаларны үз теләкләре буенча мөстәкыйль һәм иҗади рәвештә уйлаган нәрсәләрен ясарга өйрәтү. Бәйрәм хисе, кемнедер сөендерәсе килү хисен уяту. |
| | “Курчак” | Ике өлештән торган предмет әвәләү (шар - баш, столбик - тун). |

| | | |
|---|---|---|
| январь | “Минем яраткан әкият героем” | Балаларның үзләре сайлаган әкияттән үзләренә ошаган әкият героен әвәләргә өйрәтү.Аның гәүдә формасын, кул, аякларын дөрес итеп тасвирлый белергә өйрәтү; әкиятләрне хәтерләрендә яңартырга ярдәм итү; әкият геройларының уңай һәм тискәре якларын күрә һәм бәяли белергә күнектерү. |
| | “Азык –төлек кибетенә тәм –томнар киледе” | Татар халык ашлары белән таныштыруны дәвам итү; кул чукларының физик үсешен ныгыту. Халык ашларына хөрмәт тәрбияләү. |
| февраль | “Кошлар җимлеккә очып килделәр” | Әвәләүдә гади торышны: гәүдәне аска, башны иргә, иптәшеңнең эше белән үз эшеңне берләштерергә өйрәтү. Әвәләү алымнарының техникасын ныгыту. |
| | “Яраткан йорт хайваным” | Хайван өлешләрен өйрәнгән алымнар белән әвәләү, хайваннарга карата сакчыл караш тәрбияләү. |
| | “Самолетлар аэродромда” | Ике кисәк пластилиннан самолет әвәләргә өйрәтү |
| | “Үзеңә нәрсә ошый, шуны әвәлә” | Үз фикерләреңне туплый белүне үстерү,әдәби әсәрләрдән алган тәэсирләрне формалаштыру. Алда өйрәнгән алымнарны кулланып кызыклы әйберләр әвәләүне ныгыту. |

“Чынаяк(чокыр)” Тәгәрәтү алымы белән савыт – саба әвәләргә өйрәтү. Кырыйларын тигезләп формага китерү. Өлешләрен беркетү һәм шомартуны ныгыту. Кул чуклары
хезмәтен камилләштерү.

“Чәчәк бәйләме” Тюльпан чәчәге әвәләргә өйрәтү, әниләргә хөрмәт тәрбияләү.

“Куян баласы” Гәүдә өлешен дөрес әвәләргә өйрәтү, куянга хас үзенчәлекләрне ачыклау, хайваннарга карата сакчыл караш тәрбияләү.

“Кәҗә бәтие” Дүрт аяклы хайван әвәләргә өйрәтү(гәүдәсе овал,башы озынча, тәпиләре туры);әвәләү алымнарын ныгыту; уч төпләрендә әйләндерү; аерым өлешләрен гәүдәгә беркетү; беркеткәч шомартып кую.

| | | |
|---|---|---|
| | | |
| | | |
| апрель | “3 аюга савыт әвәләү” | Бер төрле формадагы предметларны, ләкин төрле зурлыктагы предметларны әвәләргә өйрәтү; предметларны әкият буенча драматизацияләргә өйрәтү. Савытларны әвәләүне күнектерү; тәгәрәтү, сыту; кырыйларын бармаклар белән күтәрүне эшкәртү. |
| | “Тәлинкәдән кошчык җим чүпли” | Алда өйрәнгән алымнарны (тәгәрәтү, тартып чыгару,өлешләрне беркетү, шомарту) кулланып әвәли белүне ныгыту. |
| | “Чеби” | Төрле зурлыкчтагы шарлар әвәләү, бер-берсе белән тоташтыру, чеметеп койрык, томшык ясау |
| | “Матур бакчабыз” | Алда өйрәнгән алымнарны кулланып әвәләү ысулларын ныгыту. Нинди яшелчәләр белүләрен, нинди төстә икәнен ачыклау. |
| май | Ирекле | Иҗади һәм үзлегеннән эшләүне үстерүне ныгыту. Стек белән эшләргә өйрәтү. |
| | Ирекле | Иҗади һәм үзлегеннән эшләүне үстерүне ныгыту. Стек белән эшләргә өйрәтү. Алган белемнәрен куллануны ныгыту. |

# *ҖЫР*

***Аңлатма язуы***

«Музыка» белем бирү эшчәнлеге эчтәлеге балаларның музыкальлекләрен, музыканы хис-тойгы белән кабул итү сәләтләрен үстерү максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә Һәм белем бирү бурычларын билгели.

Татар музыкасына карата кызыксыну уяту, аны тыңларга теләк белдерү. Аның хисле-образлы эчтәлеге турында сөйләү, кичерешләр белән бүлешү.

Татар композиторларының музыкаль әсәрләрен тыңлап, музыканың төп өч жанры: «җыр», «бию», «марш» төшенчәләрен бирү. Балаларның музыка характерын, кәефен бирә белү сәләтләрен үстерү.

Музыка уен кораллары (курай, кубыз, тальян гармун һ. б.) һәм аларның яңгырашы белән танышуны дәвам итү. Татар җырларын дөрес, сәнгатьле итеп һәм аңлап башкарырга, сүзләрен ачык итеп әйтергә күнектерү.

Татар биюенә хас гади хәрәкәтләр («аяк очларында атлап йөрү», «чүгү», «аяк очларында күтәрелү», «берле бишек», «баш-үкчә», «култыклашып әйләнү», «борма» (гади вариант) һ. б.) белән таныштыруны дәвам итү.

Музыка характерына туры китереп, ритмлы хәрәкәтләр башкаруны формалаштыру.

Хәрәкәтле импровизацияләрдә музыкаль образны чагылдырырга омтылуны хуплау, балалар белән бергә гәүдәләнеш вариантларын («тәкәббер» әтәч, «кайгыртучан» тавыклар, тик-тормас чебиләр һ. б.) тикшерү, музыкаль әкият эчтәлеге һәм характерына дөресрәк туры килә торган образны сайларга булышу, һәр иҗади табышны хуплау.

Балалар эшчәнлегенең төрле структурасына музыка өстәү; матур әдәбият, сынлы һәм театр сәнгатьләре әсәрләрен файдаланып, кәефкә туры килерлек һәм хис-кичерешләргә ярдәм итәрлек музыка астында катнаш музыкаль эшчәнлек үткәрү.

# *3.МИЛЛИ – ҖИРЛЕ КОМПОНЕНТ (НРК)*

***Аңлатма язуы***

**Тәрбияләү һәм белем бирү бурычлары:**

Туган йортка, балалар бакчасына, туган илгә мәхәббәт тәрбияләү. Туган шәһәрнең күренекле урыннары белән таныштыру.

Татар халкының мәдәниятенә, гореф –гадәтенә кызыксыну уяту. Декоратив – кулланма сәнгате белән таныштыру.

Рус халкының мәдәниятенә, гореф –гадәтенә кызыксыну уяту. Декоратив – кулланма сәнгате белән таныштыру.

Үткән буын иҗат иткән барлык әйберләргә ихтирам тәрбияләү.

| № | Белем өлкәсе | Бүлекләр | Бурычлар |
|---|---|---|---|

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1 | Физик үсеш | Сәламәтлек | Хәрәкәткә, бергә уйналучы татар халык һәм рус хәрәкәтле уеннарына кызыксынучанлык тәрбияләү. Балада уңай сыйфатлар, татар һәм рус халкының сулыш гимнастикасын, физминуткаларын, күнегүләрен куллана алу күнекмәләрен формалаштыру. |
| 2 | | Физик культура | Татар һәм рус халкының хәрәкәтле уеннары белән танышу, халык уеннарына кызыксынучанлык уяту. Балаларның иҗади фикерләүләрен. Физик сыйфатларын: тизлек, осталык, чыдамлыкларын үстерү, хәрәкәт күнекмәләрен камилләштерү. |
| 3 | Социаль -шәхси үсеш | Социальләштерү | Татарстан республикасы һәм Рәсәй турында беренче күзаллауларын формалаштыру.. Зурларга һәм яшьтәшләренә әдәпле эшдәшү, үзләрен алар белән тотнаклы тоту сыйфатларын тәрбияләү. Дуслык, дөреслек, кешелеклелек, гаделлелек тәрбияләү. |
